# КОРЪӘНДӘГЕ ДОГАЛАР

РӘҮФ ПӘҺЛЕВАН

МОТИФ ЙАЙЫНЛАРЫ

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

# КОРЪӘНДӘГЕ ДОГАЛАР

Коръән Кәримдә ике йөзгә якын дога рәвешендә бирелгән аятьләр бар. Бу аятьләрдәге догалар Аллаһка дога кылу, теләк һәм ихтыяҗларны белдерү, Аның мәрхәмәт-шәфкатенә өметләнү, чакыру, эндәшү, гыйбадәт кылу, ярдәм сорау, хәлне аңлату, Аллаһның берлеген тану, мөрәҗәгать һәм дәгъва итү мәгънәләрендә кулланыла. Бигрәк тә колның тәүбә итеп һәм ярлыкауны со-

www.darul-kutub.com

рап Аллаһка юнәлүе, Аңа үз теләкләрен белдереп, күпсанлы аять һәм догалар укуына бәйле. Әлеге аятьләрнең бер өлешендә кешеләрнең Аллаһка дога кылулары әмер ителгән, догаларның ысуллары, укылыш кагыйдәләре һәм тәэсире китерелгән («Бакара» («Сыер») сүрәсе, 186 нчы аять; «Ниса» («Хатыннар») сүрәсе, 4 нче аять; «Йосыф» сүрәсе, 86 нчы аять). Кайбер аятьләрдә урыны һәм вакыты билгесез, рөхсәт ителмәгән догалар турында әйтелгән. Кайберләрендә исә ахирәт өчен борчылу белдерелгән догалар китерелгән. Аятьләрнең берничәсендә пәйгамбәрләрнең һәм башка изге һәм тугрылыклы кешеләрнең догалары бирелгән. Шуларның егерме берендә – Хәзрәти Мусаның, унҗидесендә – Хәзрәти Ибраһимнең, уналтысында – Хәзрәти Гайсәнең, уникесендә – Хәзрәти Нухның, тугызында – Хәзрәти Зәкәрийянең догалары китерелгән. Бигрәк тә, Хәзрәти

www.darul-kutub.com

Адәм, Хәзрәти Шогайб, Хәзрәти Йоныс, Хәзрәти Йосыф, Хәзрәти Әюб, Хәзрәти Лут һәм Хәзрәти Сөләйманның, Хәзрәти Мәрьям ананың, Фиргавеннең хатыны, Фиргавенгә каршы чыккан сихерчеләр, Талутның гаскәрләре, фәрештәләр, бичаралар, мазлүмнәр (золым күргән кешеләр) кебек төркемнәрнең һәм аерым кешеләрнең догалары тасвирланган.

Коръән Кәримнең кайбер сүрә һәм аятьләре үрнәк дога текстлары рәвешендә бирелгән. Болардан, мәсәлән, «Фатиха» сүрәсе, кыскача гына Аллаһ Тәгаләгә мактау әйтелгәннән соң, Аңа буйсыну һәм догадагы ихлас (самимилек), кешеләрнең тугры юлга ирешергә теләкләре, тиңе булмаган ысулдагы сүзләр белән белдерелеп, барлык мөселманнарның иң күп укый торган догасына әверелде. «Бакара» сүрәсенең 201 нче аятендәге «Йә, Раббыбыз! Безгә дөньяда матур тормыш бир һәм ахирәттә дә матур тормыш бир һәм Җәһәннәм

www.darul-kutub.com

утыннан безне сакла» дигән сүзләр «Фатиха» сүрәсеннән соң иң еш укыла торган догалардан санала.

Профессор Изутсу Коръәннең догага мөнәсәбәтен түбәндәгечә аңлаткан:

«Вәхи – Аллаһ белән кеше арасында югарыдан түбәнгә, ягъни Аллаһтан кешегә таба юнәлгән үзенчәлекле элемтә, сөйләшү. Аллаһ үз сүзләрен кешеләргә юнәлдереп, пәйгамбәрләр аша тапшырган. Ләкин Аллаһ белән кеше арасындагы әлеге мөнәсәбәт берьяклы гына булмый. Ягъни кеше бу аралашуда даими пассив калмыйча, кайвакыт Аллаһка юнәлгән сүзләрен беренче булып башлый. Кеше Аның белән сөйләшергә теләген белдерә. Шушы теләкнең нәтиҗәсендә барлыкка килгән вакыйга вәхигә охшый. Ләкин бу очракта әңгәмәнең юнәлеше астан өскә таба була. Бу сөйләшү дә, вәхи кебек үк, гадәттән тыш шартларда һәм үзенчәлекле рәвештә уза. Гадәттә, кеше

www.darul-kutub.com

Аллаһка турыдан-туры мөрәҗәгать итә алмый (???). Гадәти әңгәмәне булдыру өчен, ике тараф арасында онтологик тиңдәшлек булырга тиеш. Бу – телнең төп принцибы. Әмма шушы принципны боза алучы бер очрак барлыкка килгәндә кеше Аллаһка мөрәҗәгать итәргә мөмкин, Аның белән сөйләшү сәләтенә ия булыр. Бу гадәттән тыш хәлдә кеше үзенең башын көндәлек хәлләрдән өстен тота. Әлеге очракта кеше башы берәр киеренке халәттә эшләү нәтиҗәсендә уйлау сәләтен бөтенләй югалтырга мөмкин. Бу дәрәҗәгә җиткән кеше Тәңрегә турыдан-туры мөрәҗәгать итә ала. Әлеге очракта кеше инде гадәти хәлдәге кеше түгел. Кирмәни әйткәнчә, ул үзенең асылыннан өстен булган барлыкка ирешә. Шул рәвешле, гадәттән тыш хәл эчендә узган мондый мөрәҗәгатьне дога дип атыйлар». (Изутсу, «Коръәндә Аллаһ һәм кеше», 182)

Кешене бу хәлгә китергән һәм

www.darulkutub.com

телнең бу рәвештә кулланылуын кулай иткән сәбәпләр төрле: Аллаһка карата тирән ярату хисе дә, тәкъвалык та, үлем куркынычы да булырга мөмкин. Коръәндә Аллаһка ышанмаган мөшрик гарәпләрнең дә берәр куркыныч янаганда эчкерсез рәвештә Аллаһ Тәгаләгә ялварганнары мәгълүм:

«Әгәр Аллаһка итәгать итмәгән динсез кешегә берәр катырак зарар кагылса, ятып яки утырып, яки басып Безгә дога кыладыр, кайчан Без аның зарар вә кайгысын бетерсәк, үзенә кагылган зарар өчен Безгә дога да кылмаган кеби булып, әүвәлге азгынлыгына төшә. Әнә шулай хак юлдан чыккан кешеләрнең кылган бозык эшләре үзләренә яхшы булып күренә». («Йоныс» сүрәсе, 12 нче аять)

«Төрле яктан дулкын килсә һәм чорнап алган дулкын һәлакәте килде дип белсәләр, шул вакыт алар Аллаһ диненә кайтып, ихлас Аллаһка дога кылырга тотыналар: «Йә, Рабби,

www.darul-kutub.com

әгәр безне бу һәлакәттән коткарсаң, әлбәттә, нигъмәтләреңә шөкер кылучылардан булырбыз», – диләр». («Йоныс» сүрәсе, 22 нче аять)

Шунысы мәгълүм, бу рәвешле дога кылу кешене гадәти фикер йөртүдән аера, һәм ул гадәттән тыш очракларда була. Чөнки кеше йөрәге гадәттән тыш очракларда гадәти уй-фикерләрдән һәм дөньяви мәшәкатьләрдән арына, сөйләгән теле рухи һәм бөек үзенчәлеккә ия була. «Дога – йөрәкнең Аллаһ белән сөйләшүе». Бары тик кеше йөрәге генә гадәттән тыш очракларда дога кылырга мөмкин. Алга таба бирелгән аять шул әйтелгән сүзләргә үрнәк булып тора:

«Әгәр сезгә Аллаһның каты газабы яки куркыныч кыямәт килгәндә үзегез Илаһ дип санаган мәхлуктан ярдәм сорарсызмы? Әлбәттә, бу эшне эшләмәячәксез. Сез куркыныч вакытларда Аллаһның үзенә түбәнчелек белән коллык күрсәтәсез һәм ярдәмне

дә Аллаһтан гына сорыйсыз». («Әнгам» сүрәсе, 40-41 нче аятьләр)

«Бу рухи киеренкелек бераз гына кимеп һәм һәр нәрсә бары тик узгучы бер вакыйга буларак юкка чыгып, даими һәм нигезле тәкъвалыкка әверелгәндә, ул вакытта дога ялвару, гыйбадәт рәвешенә керә». (Изутсу, 184)

«Расүллүллаһ әйт: «Әй, мөшрикләр, сез гыйбадәт иткән Аллаһтан башка нәрсәгә гыйбадәт кылудан миңа Аллаһ тарафыннан катгый тыелган», – дип». («Әнгам» сүрәсе, 56 нчы аять)

«Аллаһ ризалыгын теләп, көндезләрен һәм кичләрен Раббыларына гыйбадәт кылган зәгыйфь яки фәкыйрь мөэминнәрне яныңнан кума!» («Әнгам» сүрәсе, 52 нче аять)

«Һәр мәчеттә йөзләрегезне кыйблага юнәлдерегез һәм динне Аллаһ ризалыгы өчен генә ихлас тотып, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз!» – диде». («Әгъраф» сүрәсе, 29 нчы аять)

www.darul-kutub.com

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ СӨННӘТЕНДӘ ДОГА

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламгә һәм аның тормышына күз салсак, доганың аның тормышындагы һәр мизгелендә очрый торган гамәл икәнен күрербез. Дога аның тормышында гадәти бер яшәү рәвешенә әйләнгән.

Хәзрәти Мөхәммәднең кайбер хәдисләрендә доганың әһәмияте аңлатылган:

«Дога – гыйбадәтнең үзе» (Тирмизи, Тәфсир: 16)

«Аллаһ катында догадан тыш ихтирамга лаек булырдай берни дә юк» (Тирмизи, Дәват: 1)

«Дога – гыйбадәтнең асылы?» (Тохфәту-л Ахвәзи: 9/311)

«Дога иңгән бәла-казалардан да,

www.darulkutub.com

иңмәгән бәхетсезлекләрдән дә саклый. Аллаһның коллары! Сезгә кирәк булган дога кылудан туктамагыз». (Әт-Тадж: 5/101)

«Һәлакәттән бары тик дога гына коткарырга мөмкин. Гомерне дә бары тик хәерле гамәлләр генә озынайта ала». (Әт-Тадж: 5/101)

«Кем куркыныч вакытларда һәм кыенлыкларга юлыкканда догасының Аллаһ тарафыннан кабул ителүен теләсә, тыныч-имин вакытта һәм муллыкта күп дога кылсын». (Тохфәту-л Ахвәзи: 9/324)

«Аллаһның мәрхәмәтеннән теләгәнегезне сорагыз. Хакыйкатьтә, Газиз һәм Җәлил булган Аллаһ үзеннән сораганны ярата. Гыйбадәтнең иң кыйммәтлесе ярлыкануны сорау». (Әт-Тадж: 5/101)

«Хәзрәти Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Гөнаһлы нәрсәләрдән яки туганлыкка каршы дога кылудан тыш, Аллаһ үз догасын кабул

www.darul-kutub.com

итмәгән хәтта бер мөселман да юктыр җир йөзендә. Аллаһ, һичшиксез, сораган кешене теләгенә ирештерер яки үзеннән шул яманлыкны кире чигерер», – дигән. Моңа каршы бер кеше: «Алайса без күп итеп дога кылыйк», – дигән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам: «Аллаһның ярдәме чиксез», – дигән. (Әт-Таҗ: 5/100)

«Дога – мөселманның коралы, диннең терәге, күкләрнең һәм җирнең нуры». (Әт-Тәргыйб: 2/479)

«Дога кылуда гаҗиз булмагыз. Чөнки дога кылган затлар беркайчан да һәлак булмас». (Әт-Тәргыйб: 2/479)

«Кол: «Йә, Раббым! Йә, Раббым! Йә, Раббым!» дигән саен, Аллаһ Тәгалә аннан: «Колым! Ни телисең? Сора!» дип әйтер һәм сораганын бирер». (Әт-Тәргыйб: 2/448)

«Кем Миңа дога кылмаса, Мин аңа ачулы булырмын». (Фәйзу-л Кадир: 4/497)

www.darul-kutub.com

Аятьләрдәге кебек, хәдисләрдә дә доганың фазыйләте, өстенлеге, кагыйдәләре, шартлары, кабул ителүе мөмкин булган һәм булмаган догалар, дога кылу өчен уңайлы вакыт, Хәзрәти Мөхәммәднең төрле урыннарда һәм вакытта, төрле хәлләрдә кылган үзенчәлекле догалары хакында мәгълүмат бирелгән. Ислам мәдәниятендә Коръән Кәримдә китерелгән дога аятьләре һәм хәдис чыганакларында бирелгән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнең догалары белән бергә пәйгамбәрләргә һәм борынгы изгеләргә кагылышы булган дога текстлары «мәгъсүр догалар» дип атала. Догаларга бәйле рәвештә барлыкка килгән әдәбиятның җыентыкларга кертелгән иң әһәмиятле һәм иң күләмле бүлеген «мәгъсүр догалар» тәшкил итә.

www.darul-kutub.com

# ДОГА АЯТЬЛӘРЕ

Әлеге догаларны Аллаһ Тәгалә безгә Коръән Кәримдә өйрәткән. Болар пәйгамбәрләр һәм алар заманындагы кайбер мөселманнар кылган догалар. Алар Коръән Кәримдәге догалар булып санала. Биредә Коръәндә китерелгән догаларны, кем тарафыннан, кайчан һәм ни өчен кылганнарыннан чыгып, аерып бирдек. Иң бөек һәм иң әһәмиятле догалар түбәндәгеләр:

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيطَانِ الرَّجِيمِ

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

الْحَمْدُ لِلهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۙ* الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ ۙ* مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ * إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ* إِهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ ۙ*صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ ۙغَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ

www.darulkutub.com

**«Әлхәмду лилләһи раббил гәәләмиин әр-рахмәәнир-рахиим, мәәлики йәүмиддиин. Иййәәкә нәгьбүду үә иййәәкә нәстәгиин. Иһдинә-с сыйраатал-ль мүстәкыйм, сыйрааталләзиинә әнгәмтә гәләйһим гайри-ль мәгъдууби гәләйһим үә лә-д даааллин. (Әмин)»**

*«Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм эшемне. Чын мактау галәмнәрне, барлык мәхлукларны тәрбияләүче Аллаһ Тәгаләгә тиешле. Аллаһ Тәгалә бу дөньяда барча кешеләргә мәрхәмәтле, ягъни мөэминнәргә дә, кяферләргә дә нигъмәтләрен бирә, әмма Ахирәттә мөэмин бәндәләренә генә бирәчәк. Аллаһ Тәгалә гаделлек белән хөкем итүче, кыямәт көненең патшасыдыр. Әй, тәрбиячебез Аллаһ! Без Сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм һәр эшебездә Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Әй, тәрбиячебез Аллаһ! Безне тугры юлга күндер! (Тугры юл – Коръән һәм Сөннәт юлы) Ул юлны Син әүвәлгеләргә ингам итеп бирдең, безне Синең ачуың төшкән вә адашкан кешеләрнең бидәгать һәм заләләт юлыннан башка юлга күндер, ягъни Сине ачуландырмаган һәм хак юлдан адашмаган кешеләр юлына күндер! Әмин.» («Фатиха» сурәсе, 1-7 нче аятьләр)*



www.darul-kutub.com

## Хәзрәти Адәмнең белеменнән хайран калган фәрештәләрнең догасы

سُبْحَانَكَ لاَ عِلْمَ لَنَا إِلاَّ مَا عَلَّمْتَنَا إِنَّكَ أَنْتَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ

**«Сүбхәәнәкә ләә гильмә ләнәәә илләә мәә гәлләмтәнәә иннәкә әңтә-ль гәлиимү-ль хәкиим»**

*«Фәрештәләр әйттеләр: «Әй, һәр кимчелектән пакь булган Раббыбыз! Бездә һич белем юк, мәгәр Син белдергәнне генә beләбез, Син, әлбәттә, һәр нәрсәне белүче, хикмәт белән эш кылучы». («Бакара» сүрәсе, 32 нче аять)*

## Хәзрәти Ибраһимнең Кәгъбә нигезе янында кылган догасы

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәлам углы Исмәгыйль галәйһиссәлам белән бергә Кәгъбәнең нигезләрен күтәргәндә шушы доганы кылганнар:

رَبَّنَا تَقَبَّلْ مِنَّا إِنَّكَ أَنْتَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ



www.darulkutub.com

**«Раббәнәә тәкаббәл миннәә. Иннәкә әңтә-с сәмигү-ль гәлиим»**

*«Әй, Раббыбыз! Эшебезне кабул ит! Син ишетүче һәм күңелләрне белүче». («Бакара» сурәсе, 127 нче аять)*

Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам Кәгъбәне төзеп бетергәч кылган дога:

رَبَّنَا وَاجْعَلْنَا مُسْلِمَيْنِ لَكَ وَمِنْ ذُرِّيَّتِنَا أُمَّةً مُسْلِمَةً لَكَ ص وَأَرِنَا مَنَاسِكَنَا وَتُبْ عَلَيْنَا إِنَّكَ أَنْتَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ * رَبَّنَا وَابْعَثْ فِيهِمْ رَسُولًا مِنْهُمْ يَتْلُو عَلَيْهِمْ آيَاتِكَ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَيُزَكِّيهِمْ ط إِنَّكَ أَنْتَ الْعَزِيزُ الْحَكِيم

**«Раббәнәә үәҗгәльнәә мүслимәйни ләкә үә миң зүррийәтинәә үммәтәм мүслимәтәл ләк. Үә әринәә мәнәәсикәнәә үә түб галәйнәәә иннәкә әңтә-т тәүүәәбү-р рахиим. Раббәнәә үәбгәс фииһим расүүләм минһүм йәтлүү гәләйһим әәйәәтикә үә йүгәллимүһүмү-ль китәәбә үә-ль хикмәтә үә йүзәккииһим. Иннәкә әңтә-ль гәзиизү-ль хәкииим».**

*«Әй, Раббыбыз! Икебезне дә үзеңә итәгать итүче мөселманнардан кыл һәм нәселебездән дә мөселман булган җәмәгатьне насыйп ит һәм безгә хаҗ гамәлләрен өйрәт вә тәүбәләребезне кабул итеп гөнаһларыбызны гафу ит! Син, әлбәттә, тәүбәләрне кабул итүче, рәхимлесең. Әй, Раббыбыз! Бездән соң нәселебезгә үзләре арасыннан пәйгамбәр күндер! Ул пәйгамбәр аларга Синең китабыңны өйрәтер һәм Ислам диненең бөтен хөкемнәрен һәм аларны мөшриклектән, бидгать гамәлләрдән һәм хәрам нәҗесләрдән пакьләр». («Бакара» сүрәсе, 128-129 нчы аятьләр)*

## Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнең дөнья һәм ахирәткә кагылышлы догалары

رَبَّنَا اٰتِنَا فِى الدُّنْيَا حَسَنَةً وَ فِى الاَخِرَةِ حَسَنَةً وَ قِنَا عَذابَ النَّرِ

**«Раббәнәәә әәтинәә фи-д дүнйәә хасәнәтәү үә фи-л әәхыйрати хасәнәтәү үә кыйнәә гәзәәбә-н нәәр».**



www.darul-kutub.com

*«Әй, Раббыбыз! Безгә дөньяда матур тормыш бир һәм ахирәттә дә матур тормыш бир һәм Җәһәннәм утыннан безне сакла». («Әл-Бакара» сурәсе, 201 нче аять)*

## Җалутка каршы чыккан мөселманнарның догасы

Зур сынаулар белән очрашканнан соң, Җалутның көчле урдасына каршы чыккан мөселман башчысы Талутның аргта калган бер төркем гаскәрләренә каршы кылган догсы. Хәзрәти Давуд галәйһиссәлам дә Талут гаскәрләре арасында булган. Коръәндә әйтелгәнчә, Хәзрәти Давуд галәйһиссәлам Җалутны үтергән һәм Талутның урдасы җиңүгә ирешкән.

رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبرًا وَ ثَبِّتْ أَقْدَمَنَا وَ انْصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ

**«Раббәнәәә әфригъ гәләйнәә сабьрау үә сәббит әкъдәәмәнәә үәңсурнәә галә-ль кауми-ль кәәфириин»**



www.darulkutub.com

*«Әй, Раббыбыз! Безгә сабырлык, батырлык бир һәм аякларыбызны нык беркет һәм кяфер каумен җиңәргә ярдәм бир». («Әл-Бакара» сурәсе, 250 нче аять)*

## Пәйгамбәрләр һәм тәкъва мөселманнары догасы

Әлеге доганы мөселманнар ясту намазыннан соң укый һәм тыңлый торган булганнар:

رَبَّنَا لاَ تُؤَاخِذْنَا أَوْ أَخْطَأْنَا رَبَّنَا وَ لاَ تَحْمِلْ عَلَيْنَا إِصْرًا
كِمَا حَمَلْتَهُ عَلَى الَّذِينَ مِنْ قَبْلِنَا رَبَّنَا وَ لاَ تُحَمِّلْنَا مَا لاَ
طَاقَةَ لَنَا بِهِ وَ اعْفُ عَنَّاۗ وَ اغْفِرْ لَنَاۗ وَ ارْحَمْنَاۗ أَنْتَ
مَوْلَيْنَا فَانْصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ

**«Раббәнәә ләә түәәхыйзьнәә ин нәсийнәәә әү әхътаәнәә. Раббәнәә үә ләә тәхмил галәйнәәә исраң кәмәә хәмәлтәһү гәләл ләзиинә миң кабьлинәә. Раббәнәә үә ләә түхәммилнәә мәә ләә таакатә ләнәә биһ. Үәгьфү гәннәә, үәгъфирләнәә, үәрхәмнәә. Әңтә мәүләәнәә фәңсурнә галә-ль кауми-ль кәәфириин».**

www.darul-kutub.com

*«Йә Раббым! Онытып яисә ялгышып кылган гөнаһларыбыз өчен гафу кыл. Йә Раббым! Безгә бездән алдагыларга йөкләгән кебек авыр сына-улар бирмә. Йә Раббым! Көчебез җитми торган кыенлыкларга юлыктырма. Безне гафу ит. Безгә мәрхәмәт-шәфкатеңне иңдер. Безне сакла. Син безнең хуҗабыз. Кяферләргә каршы торуда безгә ярдәм ит».*

## Туры юлдан тайпылмаган галимнәрнең догасы

Тирән гыйльми белемле һәм йөрәк-ләрендә бернинди дә хилафлык булма-ган галимнәр кылган дога:

رَبَّنَا لاَ تُزِغْ قُلُوبَنَا بَعْدَ إِذْ هَدَيْتَنَا وَ هبْ لَنَا مِنْ لَدُنْكَ رَحْمَةً إِنَّكَ أَنْتَ الْوَهَّابُ

**«Раббәнәә ләә түзигъ кулүүбәнәә багъдә из һәдәйтәнәә үә һәб ләнәә мил ләдүңкә рахмәһ. Иннәкә әңтә-л үәһһәәб»**

*«Әй, Раббыбыз! Безне тугры юлга кундергәнеңнән соң күңелләребезне дөреслектән*



www.darul-kutub.com

*ялган якка авыштырма һәм шәфкать кылып, безгә рәхмәтеңне бир! Әлбәттә, Син сорап та, сорамыйча да бирүчесең». («Әл-Гыймран» сүрәсе, 8 нче аять)*

Алга таба әлеге затларның догасы шулай дәвам итә:

رَبَّنَا إِنَّكَ جَامِعُ النَّاسِ لِيَوْمٍ لاَ رَيْبَ فِيهِ إِنَّ اللهَ لاَ يُخْلِفُ الْمِيعَادَ

**«Раббәнәәә иннәкә җәәмигү-н нәәси лийәүмил ләә райбә фииһ. Инналлаһә ләә йүхълифү-л мийгәәд»**

*«Әй, Раббыбыз! Шиксез булачак кыямәт көнендә барча кешеләрне хисап өчен бер урынга җыячаксың. Аллаһ, әлбәттә, вәгъдәсенә хилафлык кылмый». («Әл-Гыймран» сүрәсе, 9 нчы аять)*

## Тәкъва мөселманнары догасы

رَبَّنَا إِنَّنَا آمَنَّا فَاغْفِرْ لَنَا ذُنُوبَنَا وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«Раббәнә иннәнә амәннә фәгъфир ләнә зунубәнә вә кыйннә газабә-н нар».**

www.darul-kutub.com

*«Җәннәтләргә кертеләчәк мөэминнәр әйтәләр: «Әй, Раббыбыз! Без, әлбәттә, Сиңа һәм расулеңә иман китердек. Безне ярлыка, гөнаһларыбызны гафу ит һәм безне җәһәннәм утыннан сакла!» («Әл-Гыймран» сурәсе, 16 нчы аять)*

## Коръәндә Пәйгамбәребезгә укырга боерылган дога

«Фатиха» сүрәсендәге кебек, Аллаһ Тәгалә пәйгамбәрләрнең теле белән барлык мөселманнарның үтенеч-ялваруларын белдергән. Аллаһ Тәгалә боерган:

«Расүлем әйт:

اللَّهُمَّ مَالِكَ الْمُلْكِ تُؤْتِي الْمُلْكَ مَنْ تَشَاءُ وَتَنْزِعُ الْمُلْكَ
مِمَّنْ تَشَاءُ ز وَتُعِزُّ مَنْ تَشَاءُ وَتُذِلُّ مَنْ تَشَاءُ ط بِيَدِكَ الْخَيْرُ ط
إِنَّكَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ * تُولِجُ اللَّيْلَ فِي النَّهَارِ وَتُولِجُ
النَّهَارَ فِي اللَّيْلِ ز وَتُخْرِجُ الْحَيَّ ز مِنَ الْمَيِّتِ وَتُخْرِجُ الْمَيِّتَ
مِنَ الْحَيِّ ز وَتَرْزُقُ مَنْ تَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ

**«Аллаһуммә мәәликә-л мүлки түэти-ль мүлкә мәң тәшәәә-ү үә тәңзигү-ль мүлкә миммән тәшәәә-ү**



www.darul-kutub.com

**үә түгиззү мәң тәшәәә-ү үә түзиллү мәң тәшәәә-э. Бийәдикә-ль хайр. Иннәкә гәләә күлли шәй иң кадиир. Түүлиҗү-л ләйлә фин нәһәәри үә түүлиҗү-н нәһәәра фи-л ләйл. Үә түхъриҗү-ль хәййә минә-ль мәййити үә түхъриҗү-ль мәййитә минә-ль хәйй. Үә тәрзүку мәң тәшәәә-ү би гайри хисәәб».**

*«Әй, Аллаһ, син барча байлыкның патшасы: Үзең теләгән кешегә байлыкны бирәсең һәм Үзең теләгән кешедән байлыкны аласың. Барча хәйрият Синең кулында, шиксез, Синең һәр нәрсәгә көчең җитә. Син кичне көнгә, көнне кичкә кертәсең, үлекне теректән чыгарасың, һәм терекне үлектән чыгарасың, һәм дә теләгән бәндәләреңә хисапсыз ризык бирәсең». («Гыймран» сурәсе, 26-27 нче аятьләр)*

## Хәзрәти Мәрьям тугач кылынган дога

إِنِّي أُعِيذُ بِكَ وَذُرِّيَّتَهَا مِنْ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

**«Иннә әгузу бикә вә зурриййәтәһә минә-ш шайтани-р раҗим».**

*«Әй, Раббым! Бу баланы һәм аннан туачак ба-*

www.darulkutub.com

*лаларны рәхмәтеңнән сөрелгән шайтан явызлыгыннан Синең саклавыңа тапшырдым». («Гыймран» сурәсе, 36 нчы аять)*

## Хәзрәти Зәкәрийянең бала сорап кылган догасы

Зәкәрийя галәйһиссәлам Аллаһ Тәгаләдән саф нәсел сораган:

رَبِّ هَبْ لِي مِنْ لَدُنْكَ ذُرِّيَّةً طَيِّبَةً إِنَّكَ سَمِيعُ الدُّعَاءِ

**«Рабби һәб лии мил лядүңкә зүррийййәтәң таййибәһ. Иннәкә сәмиигү-дүгәәә-э»**

*«Әй, Раббым, рәхмәтеңнән миңа бер бала бир! Шиксез, син минем догамны ишетәсең». («Гыймран» сурәсе, 38 нче аять)*

## Хәвариләр (Гайсә пәйгамбәрнең шәкертләре) догасы

Хәзрәти Гайсә галәйһиссәламгә иман китергән хәвариләр догасы. Барлык мөселманнар өчен үрнәк дога:

رَبَّنَا آمَنَّا بِمَا أَنْزَلْتَ وَاتَّبَعْنَا الرَّسُولَ فَاكْتُبْنَا مَعَ الشَّاهِدِينَ



www.darulkutub.com

**«Раббәнәәә әәмәннәә бимәәәә әңзәлтә үәттәбәгьнә-р расүүлә фәктүбнәә мәгә-ш шәәһхидиин»**

*«Әй, Раббыбыз, син иңдергән китапларга ышандык һәм пәйгамбәргә иярдек. Безне Синең берлегең һәм исламның хаклыгы белән шәһадәт бирүче мөселманнар белән бергә кыл!» («Гыймран» сүрәсе, 53 нче аять)*

## Гаделсезлеккә дучар булган мөселманнарның догасы

Пәйгамбәрләр белән бергә җиһад кылган, күп газапларга дучар ителгән ярдәмчеләренең кылган догалары:

اغْفِرْ لَنَا ذُنُوبَنَا وَإِسْرَافَنَا فِي أَمْرِنَا وَثَبِّتْ أَقْدَامَنَا وَانْصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ

**«Раббәнәгъфир ләнәә зүнүүбәнәә үә исраафәнәә фиии әмринәә үә сәббит әкъдәәмәнәә үәңсурнәә гәлә-ль кауми-ль кәәфириин»**

*«Әй, Раббыбыз, гөнаһларыбызны һәм эшләребездә чиктән утуләребезне ярлыка, сугыш сафларында аякларыбызны таза кыл һәм кәферләрне*



www.darul-kutub.com

*җиңәргә безгә ярдәм бир!» («Гыймран» сурәсе, 147 нче аять)*

Алга таба китерелгән аятьтә аларның догаларының кабул ителүе, аларга дөнья савабы да, ахирәт савабы да бирелүе турында әйтелгән:

فَاٰتٰيهُمُ اللّٰهُ ثَوَابَ الدُّنْيَا وَحُسْنَ ثَوَابِ الْاٰخِرَةِ وَاللّٰهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ ۝

**«Фә әәтәәһүмүллаһу сәүәәбә-д дуньйәә үә хүснә сәүәәби-ль әәхыйраһ. Үаллаһу йүхиббү-ль мүхсиниин»**

*«Аллаһ аларга дөнья нигъмәтләрен бирде һәм ахирәтнең мәңгелек яхшы нигъмәтләрен дә бирде. Коръән юлы белән изге гамәлләр кылучы мөэминнәрне Аллаһ, әлбәттә, сөя». («Гыймран» сурәсе, 148 нче аять)*

## Гыйбрәт күрә белүче аңлы мөселманнар догасы

Сәламәт акыллы һәм Аллаһ Тәгаләне даими зикер иткән мөселманнар кылган дога:



www.darul-kutub.com

رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«Раббәнәә мәә халәкътә һәәзәә бәәтыләә. Сүбхәәнәкә фәкыйнәә гәзәәбә-н нәәр»**

*«Әй, Раббыбыз! Бу төзелешне Син максатсыз бушка гына төземәдең. Мактау Сиңа, Син барча кимчелектән пакь! Безне ут газабыннан сакла». («Гыймран» сурәсе, 191 нче аять)*

Шушы ук мөселманнарның кылган башка догалары:

رَبَّنَا إِنَّكَ مَنْ تُدْخِلْ النَّارَ فَقَدْ أَخْزَيْتَهُ وَمَا لِلظَّالِمِينَ مِنْ أَنْصَارٍ

**«Раббәнәәә иннәкә мәң түдхыйли-н нәәра фәкадь әхъзәйтәһ. Үә мәә ли-з заалимиинә мин әңсаар»**

*«Әй, Раббыбыз, бер кешене җәһәннәм утына салсаң, тереклектә Син аны һәлак иттең. Залимнәрнең ярдәмчесе юк». («Гыймран» сурәсе, 192 нче аять)*



www.darulkutub.com

Сәламәт акыллы һәм камил иманлы мөселманнар кылган тагын бер дога:

فَاغْفِرْ لَنَا ذُنُوبَنَا وَكَفِّرْ عَنَّا سَيِّئَاتِنَا وَتَوَفَّنَا مَعَ الْأَبْرَارِ* رَبَّنَا وَآتِنَا مَا وَعَدْتَنَا عَلَى رُسُلِكَ وَلَا تُخْزِنَا يَوْمَ الْقِيَامَةِ إِنَّكَ لَا تُخْلِفُ الْمِيعَادَ

**«Раббәнәә фәгъфир ләнәә зүнүүбәнәә үә кәффир гәннәә сәййиәәтинәә үә тәәффәнәә мәгә-ль әбраар. Раббәнәә үә әәтинәә мәә үәгәттәнәә гәләә русүликә үә ләә түхъзинәә йәүмәл кыйәәмәһ»**

*«Әй, Раббыбыз, гөнаһларыбызны ярлыка һәм яхшы эшләребезне начар эшләребезгә кәффарәт ит һәм изге кешеләр җөмләсеннән утер! Әй, Раббыбыз, рәсулләрең аша безгә вәгъдә иткән җәннәтне дә бир һәм кыямәт көнне безне хур итмә! Син, әлбәттә, вәгъдәңне бозмыйсың». («Гыймран» сурәсе, 193-194 нче аятьләр)*

## Җәберләнгән кешеләрнең золымнан котылу өчен кылган догасы

رَبَّنَا أَخْرِجْنَا مِنْ هَذِهِ الْقَرْيَةِ الظَّالِمِ أَهْلُهَا وَاجْعَل لَنَا مِنْ لَدُنْكَ وَلِيًّا وَاجْعَل لَنَا مِنْ لَدُنْكَ نَصِيرًا

**«Раббәнәәә әхъриҗнәә мин һәәзиһи-ль карьйәти-з заалими әһлүһәә үәҗгал ләнә мин ләдункә вәлиййән вәҗгал ләнә мил ләдүңкә нәсыйраа»**

*«Әй, Раббыбыз, хуҗалары залим булган шәһәрдән безне чыгар. Безне залимнәр кулыннан коткаручы бер вәли бир һәм үз хозурыңнан безгә ярдәм дә бир». («Ниса» (Хатыннар) сурәсе, 75 нче аять)*

## Хәзрәти Мусаның имансызлар кавеменә каршы кылган догасы

Хәзрәти Муса галәйһиссәламнең Фиргавен золымына каршы үзенә дә, кардәше Хәзрәти Харун галәйһиссәламгә дә ярдәмче булмаган имансызлар төркеменә карата кылган догасы:

إِنِّي لَا أَمْلِكُ إِلَّا نَفْسِي وَأَخِى فَافْرُقْ بَيْنَنَا وَبَيْنَ الْقَوْمِ الْفَاسِقِينَ

**«Рабби иннии ләәә әмликү иллә нәфсии үә әхый фәфрукъ бәйнәнәә үә бәйнә-ль кауми-ль фәәсикыйн».**

www.darul-kutub.com

*«Әй, Раббым! Мин фәкать үземә һәм кардәшемә ихтыярлымын, башкача һич сүзем үтми. Фасикъ белән безнең араны аер». («Маидә» сүрәсе, 25 нче аять)*

## Хәзрәти Гайсәнең ризык сорау догасы

Бу доганы Хәзрәти Гайсә галәйһиссәлам Аллаһ Тәгаләдән ризык сорау өчен кылган. Аллаһ тарафыннан кабул ителгән дога. Ризык догасы буларак кулланылырга мөмкин:

اللَّهُمَّ رَبَّنَا أَنزِلْ عَلَيْنَا مَائِدَةً مِنْ السَّمَاءِ تَكُونُ لَنَا عِيدًا لِأَوَّلِنَا وَاٰخِرِنَا وَاٰيَةً مِنْكَ وَارْزُقْنَا وَأَنْتَ خَيرُ الرَّازِقِينَ

**«Аллаһуммә раббәнәәә әнзиль гәләйнәә мәәәидәтәм минә-с сәмәәәи тәкүүнү ләнәә гиидәл лиәүүәлинәә үә әәхыйринәә үә әәйәтәм миңкә үәрзүкънәә үә әңтә хайру-р раазикыйн»**

*«Әй, тәрбиячебез – Аллаһ! Безгә күктән ашъяулыгы белән ризык иңдер: ризык иңгән көн әүвәлгеләребезгә дә, ахыргыларыбызга да бәйрәм*

www.darul-kutub.com

*көне булсын! Әй, Раббыбыз! Безне ризыкландыр, Син, әлбәттә, ризыкландыручыларның иң хәерлесе». («Маидә» сурәсе, 114 нче аять)*

## Пәйгамбәребезнең Мәккәдә кылган догасы

Бу доганы Аллаһ Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламга өйрәткән һәм боерган:

إِنَّ صَلَاتِى وَنُسُكِى وَمَحْيَاى وَمَمَاتِى لِلهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Иннә саләәтии үә нүсүкии үә мәхьйәәйә үә мәмәәтии лилләһи рабби-ль гәәләмиин»**

*«Укыган намазларым һәм бугазлаган корбаннарым фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә эшләнә, тере булуым һәм үлүем бөтен галәмнәрне тәрбия кылучы Аллаһ Тәгалә эшедер» («Әнгам» сурәсе, 162 нче аять)*

## Хәзрәти Адәм белән Хәзрәти Һаваның кылган догалары

رَبَّنَا ظَلَمْنَا أَنفُسَنَا وَإِنْ لَمْ تَغْفِرْ لَنَا وَتَرْحَمْنَا لَنَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«Раббәнәә заләмнәәә әңфүсәнәә үә ил ләм тәгъфир ләнәә үә тәрхәмнәә ләнәкүүнәннә минә-ль хаасириин»**

*«Әй, Раббыбыз, үзебезгә золым кылдык, әгәр безне ярлыкамасаң һәм рәхмәт кылмасаң, әлбәттә, бәхетсезләрдән булачакбыз». («Әгъраф» сурәсе, 23 нче аять)*

## Җәннәткә лаек булганнарның Җәһәннәм әһелләрен күргәч кылган догалары

Җәннәттәге мөселманнар, Җәһәннәмгә эләккәннәрне күргәч, Аллаһка сыенып, түбәндәгечә дога кылырлар:

رَبَّنَا لَا تَجْعَلْنَا مَعَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

**«Раббәнәә ләә тәҗгәльнәә мәгә-ль кауми-з залимиин»**

*«Әй, Раббыбыз! Безне залим кавемнәр белән бергә кылма». («Әгъраф» сурәсе, 47 нче аять)*



www.darul-kutub.com

## Хәзрәти Шогайбның җәберләүчеләр кавеменә каршы кылган догасы

Аңа: «Әй, Шогәйб, үзеңне һәм сиңа ияреп иман китергәннәрне шәһәребездән чыгарырбыз, яки безнең динебезгә кайтарылырсыз», – дип әйтүчеләргә каршы болай дога кылган:

عَلَى اللهِ تَوَكَّلْنَا رَبَّنَا افْتَحْ بَيْنَنَا وَبَيْنَ قَوْمِنَا بِالْحَقِّ وَأَنْتَ خَيْرُ الْفَاتِحِينَ

**«Гәләллаһи тәүәккәлнәә. Раббәнәә фтәх бәйнәнәә үә бәйнә кауминәә би-ль хәккый үә әңтә хайру-ль фәәтихиин»**

*«Без Аллаһка тәвәккәл кылдык, сездән курыкмыйбыз. Әй, Раббыбыз! Безнең белән кайбер кавемебез арасында булган хәлне хаклык белән хөкем ит! Син, әлбәттә, эшне ачыклаучыларның хәерлесе». («Әгъраф» сурәсе, 89 нчы аять)*

www.darul-kutub.com

## Хәзрәти Мусага инанган сихерчеләрнең догасы

Хәзрәти Муса галәйһиссәлам күрсәткән могҗизалардан аптырап калган сихерчеләрнең, аңа иман китереп, кылган догалары:

رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبْرًا وَتَوَفَّنَا مُسْلِمِينَ

**«Раббәнәәә әфригъ гәләйнәә сабьрау үә тәүәффәнәә мүслимиин».**

*«Әй, Раббыбыз! Газабка чыдарга безгә сабырлык бир һәм безне мөселман булган хәлебездә үтер!» («Әгъраф» сүрәсе, 126 нчы аять)*

## Хәзрәти Мусаның Раббысы Бөеклегеннән тәэсирләнеп кылган догасы

سُبْحَانَكَ تُبْتُ إِلَيْكَ وَأَنَا أَوَّلُ الْمُؤْمِنِينَ

**«Сүбхәәнәкә түбтү иләйкә үә әнә әүүәлү-ль мүэминиин».**

www.darul-kutup.com

*«Әй, Раббым! Сине һәрбер кимчелектән пакь дип беләм, Сиңа тәүбә иттем һәм мин өммәтем арасында иң әувәлге мөэмин». («Әгъраф» сурәсе, 143 нче аять)*

## Кавеменең кылган гамәлләреннән борчылган/кайгырган Хәзрәти Мусаның догасы

رَبِّ اغْفِرْ لِى وَلِأَخِى وَأَدْخِلْنَا فِى رَحْمَتِكَ وَأَنْتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«Рабби гъфир лии үә лиәхии үә әдьхыйлнәә фии рахмәтикә үә әңтә әрхәмү-р раахимиин».**

*«Йә, Раббым! Мине һәм кардәшем Һарунны ярлыка, безне рәхмәтеңә кергез! Син рәхим кылучыларның иң рәхимлесе!» («Әгъраф» сурәсе, 151 нче аять)*

## Кавеменең кылган гамәлләреннән борчылган Хәзрәти Мусаның догасы

أَنْتَ وَلِيُّنَا فَاغْفِرْ لَنَا وَارْحَمْنَا وَأَنْتَ خَيرُ الْغَافِرِينَ

www.darul-kutub.com

**«Әңтә үәлиййүнәә фәгъфир ләнәә үәрхәмнәә үә әңтә хайру-л гаафириин».**

*«Син генә безнең ярдәмчебез, безне ярлыка вә рәхмәт кыл! Син ярлыкаучыларның иң хәерлесе!» («Әгърәф» сурәсе, 155 нче аять)*

Аннан соңгы аятьтә дога бу рәвешле дәвам итә:

وَاكْتُبْ لَنَا فِى هٰذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِى الْاٰخِرَةِ إِنَّا هُدْنَا إِلَيْكَ

**«Үәктүб ләнәә фии һәәзиһи-д дүньйәә хәсәнәтәү үә фи-ль әәхыйрати иннәә һүднәәә иләйк».**

*«Йә, Раббым! Безгә һидәятле куркәм тормыш нәсыйп ит! һәм ахирәттә куркәм тормышны бир! Һичшиксез, без Синең хөкемнәреңә итәгать иттек, туры юлыңа кунелдек!» («Әгърәф» сурәсе, 156 нчы аять)*

## Хәзрәти Мусага инанучыларның догасы

Хәзрәти Муса галәйһиссәлам каве-



www.darulkutub.com

менә әйтте: «Әй, кавемем! Әгәр сез Аллаһка иман итеп, мөселман булсагыз, моннан ары бары тик Аңа гына тәвәккәл итегез». Кавем шул рәвешле дога кылган:

عَلَى اللهِ تَوَكَّلْنَا رَبَّنَا لَا تَجْعَلْنَا فِتْنَةً لِلْقَوْمِ الظَّالِمِينَ وَنَجِّنَا بِرَحْمَتِكَ مِنَ الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ

**«Гәләллааһи тәүәккәлнәә. Раббәнәә ләә тәҗгәлнәә фитнәтәл ли-л кауми-з заалимиин. Үә нәҗҗинәә бирахмәтикә минә-л кауми-л кәәфириин».**

*«Аллаһка тәвәккәл кылдык. Әй, Раббыбыз, безне залимнәр кулына фетнә кылма. Һәм безне кяфер кавеменнән коткар, Үзеңнең рәхмәтең белән!» («Йоныс» сурәсе, 85-86 нчы аятьләр)*

## Хәзрәти Нухның кяфер углы өчен кылган догасы

Хәзрәти Нух галәйһиссәлам кяфер углы өчен Аллаһка дога кылган. Ләкин ул дога кабул ителмәгән. Соңрак ул тагын шул рәвешле дога кылган:



www.darul-kutub.com

رَبِّ إِنِّ أَعُوذُ بِكَ أَنْ أَسْأَلَكَ مَا لَيْسَ لِي بِهِ عِلْمٌ وَإِلَّا تَغْفِرْ لِى وَتَرْحَمْنِى أَكُنْ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«Рабби инниии әгүүзү бикә ән әсь-әләкә мәә ләйсә лии биһии гильмү үә илләә тәгъфир лии үә тәрхәмнии әкүм минә-л хаасириин».**

*«Әй, Раббым, Сиңа сыгынам. Мине сакла үзем белмәгән нәрсәне Синнән сораудан. Әгәр дә Син мине ярлыкамасаң һәм рәхмәт кылмасаң, әлбәттә, мин һәлак булучылардан булырмын». («Худ» сүрәсе, 47 нче аять)*

## Үзенә тозак корылуын белгән Хәзрәти Йосыфның кылган догасы

Мисыр патшабикәсе Йосыф галәйһиссәламне үзе янына сарайга чакырган. Аңа шунда тозак корган. Бу тозак турында белеп алган Йосыф, Раббысына сыгынып, дога кылган:

رَبِّ السِّجْنُ أَحَبُّ إِلَيَّ مِمَّا يَدْعُونَنِى إِلَيْهِ وَإِلَّا تَصْرِفْ عَنِّى كَيْدَهُنَّ أَصْبُ إِلَيْهِنَّ وَأَكُنْ مِنَ الْجَاهِلِينَ



www.darul-kutub.com

**«Рабби ссиҗнү әхәббү иләййә миммә йәдгүүнәнии иләйһ. Үә илләә тәсъриф гәннии кәйдәһүннә әсъбү иләйһиннә үә әкүм минә-ль җәәһилиин».**

*«Әй, Раббым! Мине чакырган зинага караганда миңа зиндан яхшырак. Әгәр ул хатыннарның хәйләләрен миннән Үзең бетермәсәң, ул вакытта мин аларга авышырмын һәм, ярамаган эшне эшләп, җаһилләрдән булырмын». («Йосыф» сүрәсе, 33 нче аять)*

Соңрак Йосыф галәйһиссәлам шушы вакыйга белән бәйле рәвештә тагын дога кылган:

وَمَا أُبَرِّئُ نَفْسِى إِنَّ النَّفْسَ لَأَمَّارَةٌ بِالسُّوءِ إِلَّا مَا رَحِمَ رَبِّى
إِنَّ رَبِّى غَفُورٌ رَحِيمٌ

**«Үә мәәә үбәрриү нәфсии. Иннә-н нәфсә ләәммәәратүм би-с сүүүи илләә мәә рахимә раббии. Иннә раббии гафүүру-р рахиим».**

*«Әмма шулай да булса, нәфесемне дөресләмим, чөнки нәфес явызлыкка өнди. Мәгәр нәфес өндәгән*



www.darul-kutub.com

*явыз эшләрдән котылыр Раббым рәхмәт кылган кешеләр генә». («Йосыф» сурәсе, 53 нче аять)*

## Хәзрәти Йосыфның Мисыр патшасы булгач кылган догасы

Хәзрәти Йосыф галәйһиссәлам зиндannan һәм барлык бәлаләрдән котылгач, Мисырга патша булганнан соң кылган догасы:

رَبِّ قَدْ اٰتَيْتَنِي مِنَ الْمُلْكِ وَعَلَّمْتَنِي مِنْ تَأْوِيلِ الْأَحَادِيثِ
فَاطِرَ السَّمٰوَاتِ وَالْأَرْضِ أَنْتَ وَلِيِّ فِي الدُّنْيَا وَالْاٰخِرَةِ تَوَفَّنِى
مُسْلِمًا وَأَلْحِقْنِى بِالصَّالِحِينَ

**«Рабби кадь әәтәйтәнии минә-ль мүлки үә гәлләмтәнии миң тәәүиили-ль әхәәдиис. Фәәтыйра-с сәмәәүәәти үә-ль әрдый әңтә үәлиййи фи-д дүньйәә үә-ль әәхыйраһ. Тәүәффәнии мүслимәү үә әлхикъниии би-с саалихиин»**

*«Йә, Раббым! Син миңа байлык бирдең һәм төш юрауны өйрәттең. Син җир һәм күкләрне яратучы, дөньяда һәм ахирәттә Син миңа ярдәмче. Мөселман*

www.darul-kutub.com

*хәлемдә җанымны ал һәм мине изге кешеләргә тоташтыр». («Йосыф» сүрәсе, 101 нче аять)*

## Хәзрәти Ибраһимнең Кагъбәдә кылган беренче догасы

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәлам потка табынучылардан ераклашырга теләп, балаларын Харам Мәчетенә китергән һәм анда дога кылган:

رَبِّ اجْعَلْ هٰذَا الْبَلَدَ اٰمِنًا وَاجْنُبْنِي وَبَنِيَّ أَنْ نَعْبُدَ الْأَصْنَامَ * رَبِّ إِنَّهُنَّ أَضْلَلْنَ كَثِيرًا مِنَ النَّاسِ فَمَنْ تَبِعَنِي فَإِنَّهُ مِنِّي وَمَنْ عَصَانِي فَإِنَّكَ غَفُورٌ رَحِيمٌ * رَبَّنَا إِنِّي أَسْكَنتُ مِنْ ذُرِّيَّتِي بِوَادٍ غَيْرِ ذِي زَرْعٍ عِنْدَ بَيْتِكَ الْمُحَرَّمِ رَبَّنَا لِيُقِيمُوا الصَّلٰوةَ فَاجْعَلْ أَفْئِدَةً مِنَ النَّاسِ تَهْوِي إِلَيْهِمْ وَارْزُقْهُمْ مِنَ الثَّمَرَاتِ لَعَلَّهُمْ يَشْكُرُونَ * رَبَّنَا إِنَّكَ تَعْلَمُ مَا نُخْفِي وَمَا نُعْلِنُ وَمَا يَخْفٰى عَلَى اللّٰهِ مِنْ شَيْءٍ فِي الْأَرْضِ وَلَا فِي السَّمَاءِ

**«Үә из каалә Ибрааһииму рабби җгәль һәәзә-ль бәләдә әәминәү үәҗнүбнии үә бәниййә ән нәгьбүдә-ль әсънәәм. Рабби иннәһүннә әдъләлнә кәсиирам**

**минә-н нәәс. Фәмәң тәбигании фә иннәһү минни. Вә мән гәсаании фәиннәкә гафүүру-р рахиим. Раббәнәәә иннииии әскәңтү миң зүррийәтии биүәәдин гайри зи зәргин гиңдә бәйтикә-ль мүхәррами раббәнәә лийүкыймү-с саләәтә фәҗгаль әф-идәтәм минәннәәси тәһьүиии иләйһим үәрзүкъһүм минә-с сәмәраати ләгәлләһүм йәшкүрүүн. Раббәнәәә иннәкә тәгьләмү мәә нүхъфи үә мәә нүгьлинү, үә мәә йәхъфәә гәләллаһи мин шәй-иң фи-ль әрдый үә ләә фи-с сәмәәәә-и».**

*«Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Әй, Раббым, бу Мәккә шәһәрен бәла-казалардан имин кыл һәм үземне дә, балаларымны да сыннарга гыйбадәт кылудан сакла! Әй, Раббым! Ул сыннар күп кешене адаштырды, кем миңа иярсә – ул минем өммәтемнәндер, вә берәү миңа иярмәсә, Синең ихтыярыңда кала: теләсәң – газаб кылырсың, теләсәң – ярлыкарсың. Чөнки Син ярлыкаучы рәхимлесең. Әй, Раббым! Кайбер балаларымны иген үсми торган җиргә Кагъбә янына, ягъни Кагъбә төзеләчәк чокыр җиргә илтеп куйдым (Һаҗәр белән баласы Исмәгыйльне).*

Әй, Раббым, аларга тәүфыйк бир

намазларын үтәргә һәм адәмнәрнең күңеленә аларның мәхәббәтен сал. Шул Кагъбә җиренә барып сәүдә итеп, кардәшлекне арттырып тормышларын киңәйтсеннәр һәм аларга җимешләрдән ризык бир, шаять Сиңа шөкер итәрләр. Әй, Раббыбыз! Син безнең әшкәрә кылган һәм яшерен кылган һәр эшебезне беләсең, Аллаһка җирдә һәм күкләрдә һичбер нәрсә яшерен түгел». («Ибраһим» сүрәсе, 35-38 нче аятьләр)

## Хәзрәти Ибраһимның барлык мөселманнар өчен кылган догасы

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәламнең үзе өчен дә, бөтен нәселе өчен дә кылган догасы:

رَبِّ اجْعَلْنِي مُقِيمَ الصَّلٰوةِ وَمِنْ ذُرِّيَّتِي ۚ رَبَّنَا وَتَقَبَّلْ الدُّعَاءِ
* رَبَّنَا اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابُ ۝

**«Рабби җгәлнии мүкыймә-с саләәти үә миң зүррийәти. Раббәнәә үә тәкаббәл дүгәәә-эа. Раббәнә**

www.darul-kutub.com

**гъфирлии әә лиүәәлидәййә үә ли-ль мүэминиинә йәүмә йәкуумү-ль хисәәб».**

*«Йә, Рабби! Минем үземне һәм балаларымны намазларны үтәүче кыл. Әй, Раббыбыз! Догаларыбызны кабул кыл! Әй, Раббыбыз! Үземне һәм ата-анамны һәм барча мөэминнәрне ярлыка, кыямәт көнендә хур итмә!» («Ибраһим» сүрәсе, 40-41 нче аятьләр)*

## Ата-ана өчен дога кылу

Аллаһ Тәгалә алга таба китерелгән аятьтә ата-аналар өчен дога кылу тәртибен өйрәткән һәм боерган: «Аллаһ хөкем итте һәм әмер бирде: фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» тә димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә. Бәлки аларга һәрвакыт йомшак бул, молаем сүзләр сөйлә. Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәй! Һәм әйт:

رَّبِّ ارْحَمْهُمَا كَمَا رَبَّيَانِي صَغِيرًا



www.darul-kutub.com

**«Рабби рхәмһүмәә кәмәә Раббәйәәнии сагыйра».**

*«Әй, Раббым! Алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән устергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыл!» («Бәни Исраил» (Ягъкуб балалары) сурәсе, 23-24 нче аятьләр)*

Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримдә Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламгә шулай дога кылырга әмер иткән:

رَبِّ أَدْخِلْنِي مُدْخَلَ صِدْقٍ وَأَخْرِجْنِي مُخْرَجَ صِدْقٍ وَاجْعَلْ لِي مِنْ لَدُنْكَ سُلْطَانًا نَصِيرًا

**«Рабби әдьхыйльни мүдьхалә сыйдькыйү үә әхъриҗнии мүхъраҗә сыйдькыйү үәҗгәль лии мил ләдүңкә сүльтаанән нәсыйраа».**

*«Йә, Рабби! Мине кабергә куйганда һәм кабердән чыгарганда ихлас бәндәләреңнән санап куй һәм чыгар! Дин эшләрендә ярдәм итәчәк дәлилләр бир, һәр эшемдә ярдәм бир!» («Бәни Исраил» (Ягъкуб балалары) сурәсе, 80 нче аять)*

www.darul-kutub.com

## Әсъхәәбү Кәһф кылган догалары

رَبَّنَا اٰتِنَا مِنْ لَدُنْكَ رَحْمَةً وَهَيِّئْ لَنَا مِنْ أَمْرِنَا رَشَدًا

**«Раббәнәәә әәтинәә мил ләдүңкә рахмәтәү үә һәййи ләнәә мин әмринәә рашәдәә»**

*«Әй, Раббыбыз! Үз тарафыңнан безгә рәхмәт бир һәм барча эшебезне хаклыкка сал, хаклык белән туgры юлны табарбыз» («Кәһаф» сүрәсе, 10 нчы аять)*

## Хәзрәти Мусаның телендәге тотлыгуны бетерүне сорап кылган догасы

Хәзрәти Муса галәйһиссәлам кылган догалардан берсе. Фиргавеннең золымына каршы, эшләренең уңайлашуы, телендәге сакаулыгын бетерү һәм тагын башка нәрсәләр өчен дә дога кылган:

رَبِّ اشْرَحْ لِي صَدْرِى* وَيَسِّرْ لِى أَمْرِى وَاحْلُلْ عُقْدَةً مِنْ
لِسَانِى* يَفْقَهُوا قَوْلِى ص* وَاجْعَلْ لِى وَزِيرًا مِنْ أَهْلِى*
هَارُونَ أَخِى* أُشْدُدْ بِهِ أَزْرِى

**«Рабби шраәә лии садьри. Үә йәссир лии әмрии. Үәхьлүл гүкъдәтәм мил лисәәнии. Йәфкаһүү каулии. Үәҗгәль лии үәзиирам мин әһлии. Һәруунә әхый. Үшдүд биһиии әзрии».**

*«Йә, Раббым! Кукрәгемне киң кыл залимнәрнең каршылыгына сабыр итәргә. Вә эшләремне миңа җиңел кыл. Вә телемнән төенне чиш, сөйләшүдә тотлыгуымны бетер. Тыңлаган кешеләр сүземне аңласыннар өчен. (Муса сабый чагында авызына утлы күмер капкан, шунлыктан тотлыгып сөйләшә торган булган) Миңа үз әһелемнән бер ярдәмче бир. Кардәшем Харунны. Аның белән минем куәтемне яки арт тарафымны ныгыт». («Та һа» сүрәсе, 25-31 нче аятьләр)*

## Пәйгамбәребезгә гыйлемгә кагылышлы өйрәтелгән дога

Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримдә Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламгә гыйлемгә кагылышлы шушы доганы өйрәткән:

«Расүлем! Җәбраил вәхине укып

тәмам итмәстән элек, онытырмын дип укырга ашыкма. Һәм:

رَبِّ زِدْنِي عِلْمًا

**«Рабби зиднии гильмән».**

*«Әй, Раббым! Белемемне арттыр, диген!» («Та һа» сурәсе, 114 нче аять)*

## Хәзрәти Әюбнең авыруыннан котылдыруны сорап кылган догасы

Хәзрәти Әюб галәйһиссәлам бик газаплы чиргә дучар булгач, түбәндәгечә дога кылган:

أَنِّي* مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَأَنْتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«Иннии мәссәнийә-д дурру үә әңтә әрхәмү-р рахимиин».**

*«Әй, Раббым! Мине сырхау һәм катылык тотты, Син рәхмәт итүчеләрнең иң рәхимлесе, миңа да рәхмәт ит!» («Әнбия» (Пәйгамбәрләр) сурәсе, 83 нче аять)*

www.darul-kutub.com

## Хәзрәти Йонысның балык карнында чакта кылган догасы

Хәзрәти Йоныс, балык карынында караңгылыкта калгач, дога кылган:

لَا إِلٰهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنتُ مِنْ الظَّالِمِينَ

**«Ләәә иләәһә илля әңтә сүбхәнәкә инниии күңтү минә-з заалимиин».**

*«Йә, Аллаһ! Синнән башка һич илаһ юк, бары Син генә. Сине һәр кимчелектән пакь дип беләмен, Синең рөхсәтеңнән башка кавемемне ташлап китүем белән үземә золым итүчеләрдән булдым». («Әнбия» (Пәйгамбәрләр) сурәсе, 87 нче аять)*

## Хәзрәти Зәкәрийянең бала сорап кылган догасы

Аллаһ Тәгаләдән бала сораган Зәкәррийә галәйһиссәлам шулай дога кылган:

رَبِّ لَا تَذَرْنِي فَرْدًا وَأَنْتَ خَيْرُ الْوَارِثِينَ

**«Рабби ләә тәзәрнии фәрдәү үә әңтә хайру-ль үәәрисиин».**



www.darul-kutub.com

*«Йә, Раббым! Мине баласыз ялгыз калдырма. Син варисләрнең иң хәерлесе!» («Әнбия» (Пәйгамбәрләр) сурәсе, 89 нче аять)*

## Хәзрәти Нухның үз кавеменә каршы кылган догасы

رَبِّ انْصُرْنِي بِمَا كَذَّبُون

**«Рабби ңсурнии бимәә кәззәбүүн».**

*«Әй, Раббым! Кавемем мине ялганга тотканнары өчен аларга каршы миңа ярдәм бир». («Мөэминнәр» сурәсе, 26 нчы аять)*

## Хәзрәти Нухның туфан вакытында кылган догасы

Хәзрәти Нух галәйһиссәлам туфан вакытында сулар арта барганда дога кылган:

رَبِّ انزِلْنِي مُنْزَلًا مُبَارَكًا وَأَنْتَ خَيرُ الْمُنزِلِينَ

**«Рабби әңзилнии мүңзәләм мүбәәракәү үә әңтә хайру-ль мүңзилиин»**

www.darul-kutub.com

*«Әй, Раббым! Мине мөбарәк булган урынга хәерле иңдеру белән иңдер, Син иңдеручеләрнең иң хәерлесе!» («Мөэминнәр» сурәсе, 29 нчы аять)*

## Пәйгамбәребезнең мөшрикләргә каршы кылган догасы

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламнең мөшрикләр белән көрәшкәндә Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп кылган догасы:

رَبِّ فَلَا تَجْعَلْنِي فِي الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

**«Рабби фәләә тәҗгәлнии фи-ль кауми-з заалимиин»**

*«Әй, Раббым! Мине газап ителәчәк залим кавем эченә кылма!» («Мөэминнәр» сурәсе, 94 нче аять)*

## Пәйгамбәребезнең шайтан вәсвәсәсеннән котылу өчен кылган догасы

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам шайтанның вәсвәсәсенә каршы кылган дога:



www.darul-kutub.com

رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ هَمَزَاتِ الشَّيَاطِينِ* وَأَعُوذُ بِكَ رَبِّ أَنْ يَحْضُرُونِ

**«Рабби әгүүзү бикә мин һәмәзәәти-ш шәйәәтыйн. Үә әгүүзү бикә рабби әй йәхдуруун»**

*«Йә, Раббым! Шайтаннарның вәсвәсәсеннән Синең белән сакланырмын. Әй, Раббым! Янә эшләремдә вә намазда шайтаннарның миңа якын килүләреннән Сиңа сыенам һәм Синең белән сакланам». («Мөэминнәр» сурәсе, 97-98 нче аятьләр)*

## Коръәндә мөселманнар догасы

Коръән Кәримдә Аллаһ Тәгалә тарафыннан аңлатылган кайбер мөселманнарның кылган догалары:

رَبَّنَا اٰمَنَّا فَاغْفِرْ لَنَا وَارْحَمْنَا وَأَنْتَ خَيرُ الرَّاحِمِينَ

**«Раббәнәәә әәмәннәә фәгъфир ләнәә үәрхәмнәә үә әңтә хайру-р раахимиин».**

*«Әй, Раббыбыз! Без Сиңа иман китердек, безне ярлыка һәм безгә рәхмәт ит. Син бит рәхмәт*

*итүчеләрнең хәерлесе». («Мөэминнәр» сурәсе, 109 нчы аять)*

## Коръәндә барлык мөселманнарга өйрәтелгән дога

«Мөэминнәр» сүрәсенең соңгы аятендә Аллаһ Тәгалә барлык мөселманнар да кылырлык дога өйрәткән: «Рәсүлем! Әйт:

رَبِّ اغْفِرْ وَارْحَمْ وَأَنْتَ خَيرُ الرَّاحِمِينَ

**«Раббигъфир вәрхам вә әнтә хайру-р рахимин».**

*«Әй, Раббым! Мине һәм мөэминнәрне ярлыка һәм рәхмәт ит! Син рәхмәт итүчеләрнең иң хәерлесе». («Мөэминнәр» сурәсе, 118 нче аять)*

## Тәкъва мөселманнары кыла торган дога

Аллаһның көндезен дә, төнлә дә гыйбадәт кылудан туктамаган тәкъва коллары кылган дога:

رَبَّنَا اصْرِفْ عَنَّا عَذَابَ جَهَنَّمَ ۖ إِنَّ عَذَابَهَا كَانَ غَرَامًا



www.darul-kutub.com

**«Раббәнә сърифгәннәә гәзәәбә җәһәннәм. Иннә гәзәәбәһәә кәәнә гараамәә»**

*«Әй, Раббыбыз! Бездән Җәһәннәм газабын ал. Чөнки аның газабы һәлак итүче». («Фуркан» сүрәсе, 65 нче аять)*

## Ихлас мөселманнар кылган дога

Аллаһ Тәгаләнең сүзләренә колак салган, Аның аятьләренә сукыр һәм чукрак булмаган самими мөселманнарның догасы:

رَبَّنَاهَبْ لَنَا مِنْ أَزْوَاجِنَا وَذُرِّيَّاتِنَا قُرَّةَ أَعْيُنٍ وَاجْعَلْنَا لِلْمُتَّقِينَ إِمَامًا

**«Раббәнәә һәб ләнәә мин әзүәәҗинәә үә зүрриййәәтинәә курратә әгьйүниү үәҗгәлнәә ли-ль мүттәкыйнә имәәмәә»**

*«Әй, Раббыбыз! Безгә изге хатыннар һәм яхшы балалар бир, аларның итәгать иткәннәрен күреп күзләребез һәм күңелләребез карарланырлык булсын, һәм безне тәкъва мөселманнарга имам кыл,*

www.darul-kutub.com

*алар дин эшләрендә безгә иярсеннәр». («Фуркан» сүрәсе, 74 нче аять)*

## Хәзрәти Ибраһимның хөкем догасы

رَبِّ هَبْ لِي حُكْمًا وَأَلْحِقْنِي بِالصَّالِحِينَ* وَاجْعَلْ لِي
لِسَانَ صِدْقٍ فِي الْاٰخِرِينَ* وَاجْعَلْنِي مِنْ وَرَثَةِ جَنَّةِ النَّعِيمِ*
وَاغْفِرْ لِأَبِي إِنَّهُ كَانَ مِنَ الضَّالِّينَ* وَلَا تُخْزِنِي يَوْمَ يُبْعَثُونَ*
يَوْمَ لَا يَنْفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ* إِلَّا مَنْ أَتَى اللّٰهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ

**«Рабби һәб лии хүкмәү үә әльхикъниии би-с са-алихиин. Үәҗгәль ли лисәәнә сыйдькыйң фи-ль әәхыйриин. Үәҗгәльнии миү үәрасәти җәннәти-н нәгиим. Үәгъфир лиәбии иннәһүү кәәнә минә-д дааалливн. Үә ләә түхъзинии йәүмә йүбгәсүүн. Йәүмә ләә йәңфәгү мәәлү үәләә бәнүүнә илләә мән әтәллааһә бикальбиң сәлиим».**

*«Әй, Раббым! Миңа белем-хикмәт бир һәм изгеләргә тоташтыр. Миннән соң килгән өммәтләр мине яхшылык белән зекер итсеннәр. һәм мине «нәгыйм» җәннәтенең варисларыннан кыл. һәм атамны ярлыка, чөнки ул хак юлдан адашканнардан булды. Кешеләр кубарылган көндә мине хур кылма.*

www.darulkutub.com

*Ул көндә малы һәм баласы һичкемгә файда бирмәс. Ләкин мөшриклек һәм монафикълык керләреннән күңеле пакь хәлдә чын мөселман булып килсә, аңа файда булыр». («Шугарау» сүрәсе, 83-89 нчы аятьләр)*

## Хәзрәти Лутның бозык кавеменә каршы кылган догасы

Хәзрәти Лут галәйһиссәлам бозык кавеменең кылган гамәлләреннән коткаруны үтенеп дога кылган:

رَبِّ نَجِّنِى وَأَهْلِى مِمَّا يَعْمَلُونَ

**«Рабби нәҗҗинии үә әһлии мимммәә йәгьмәлүүн»**

*«Әй, Раббым! Мине һәм өй әһелемне боларның кылган кабахәт эшләреннән һәм аларга килә торган газабтан коткар!» («Шугарау» сүрәсе, 169 нчы аять)*

## Хәзрәти Сөләйманның ата-анасы өчен кылган догасы

أَوْزِعْنِى أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِى أَنْعَمْتَ عَلَىَّ وَعَلٰى وَالِدَىَّ وَأَنْ
أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضٰيهُ وَأَدْخِلْنِى بِرَحْمَتِكَ فِى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ

www.darul-kutub.com

**«Рабби әүзигьниии ән әшкүра нигьмәтәкә лләтиии әнгәмтә гәләййә үә гәлә үәәлидәййә үә ән әгьмәлә саалихәң тәрдааһу үә әдьхыйльнии бирахмәтикә фии гибәәдикә-с саалихиин».**

*«Әй, Раббым! Үземә һәм ата-анама биргән нигъмәтләреңә шөкер иту өчен миңа илһам бир, Син риза була торган изге гамәлләр кылырга ярдәм бир һәм рәхмәтең белән мине изге бәндәләрең арасына керт!» («Нәмел» сурәсе, 19 нчы аять)*

## Хәзрәти Мусаның Мисырда кылган догасы

Хәзрәти Муса галәйһиссәлам үз тарафдарларыннан бер кешенең ярдәм соравына аның дошманын йодрыгы белән сугып үтергән. Шуннан соң ул, ярлыкау сорап, дога кылган:

رَبِّ إِنِّي ظَلَمْتُ نَفْسِي فَاغْفِرْ لِي

**«Рабби иннии заләмтү нәфсии фәгъфир лии».**

*«Әй, Раббым! Кеше үтерү сәбәпле үземә золым иттем, мине ярлыка!» («Касас» сурәсе, 16 нчы аять)*

www.darul-kutub.com

Хәзрәти Муса галәйһиссәлам ялварусын шулай дәвам иткән:

رَبِّ بِمَا أَنْعَمْتَ عَلَيَّ فَلَنْ أَكُونَ ظَهِيرًا لِلْمُجْرِمِينَ

**«Рабби бимәәә әнгәмтә гәләййә фәлән әкүүнә заһиирал ли-ль мүҗримиин»**

*«Әй, Раббым! Мине ярлыкаганың өчен мине сакла, кяферләргә ярдәмче булмасам иде» («Касас» сүрәсе, 17 нче аять)*

## Хәзрәти Лутның кавеме өчен кылган догасы

Хәзрәти Лут галәйһиссәлам җенси бозыклыкка төшкән кавеме өчен дога кылган:

رَبِّ انصُرْنِي عَلَى الْقَوْمِ الْمُفْسِدِينَ

**«Рабби ңсурнии гәлә-л кауми-ль мүфсидиин».**

*«Әй, Раббым! Миңа ярдәм бир фәхеш эшне эшләүче кавем өстенә» («Ганкәбут» сүрәсе, 30 нчы аять)*

www.darul-kutub.com

## Хәзрәти Ибраһимнең бала сорап кылган догасы

Шушы доганы кылып, Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһ Тәгаләдән бала сораган:

رَبِّ هَبْ لِى مِنْ الصَّالِحِينَ

**«Рабби һәб лии минә-с саалихиин».**

*«Әй, Раббым! Миңа бер изге бала бир, миңа ярдәмче булсын!» («Саффат» сүрәсе, 100 нче аять)*

## Фәрештәләр догасы

«Саффат» сүрәсе фәрештәләр догасы белән тәмамлана:

سُبْحَانَ رَبِّكَ رَبِّ الْعِزَّةِ عَمَّا يَصِفُونَ* وَسَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ* وَالْحَمْدُ لِلهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Сүбхәәнә раббикә рабби-ль гиззәти гәммәә йәсыйфүүн. Үә сәләәмүн гәлә-ль мүрсәлиин. Үә-ль хәмдү лилләәһи рабби-ль гәләмиин».**

*«Барча кимчелектән пакь булган, синең Раббың,*

www.darul-kutub.com

*өстенлек һәм кодрәт Раббысыдыр, Ул мөшрикләр сыйфатлаган нәрсәләрдән пакьтер. Вә барча пәйгамбәрләргә Аллаһның сәламе булсын! Вә барча галәмне тәрбия итүче Аллаһка мактау булсын!» («Саффат» сүрәсе, 180-182 нче аятьләр)*

## Хәзрәти Сөләйманның мөлкәт сорап кылган догасы

رَبِّ اغْفِرْ لِى وَهَبْ لِى مُلْكًا لَا يَنْبَغِي لِأَحَدٍ مِنْ بَعْدِى إِنَّكَ أَنْتَ الْوَهَّابُ

**«Рабби гъфир лии үә һәб лии мулкәл ләә йәмбәгый лиәхәдим мим бәгьди. Иннәкә әңтә-ль үәһһәәб».**

*«Әй, Раббым! Мине ярлыка һәм миннән соң һичкемгә лаек булмаган олугъ патшалыкны миңа бир. Һичшиксез, Син һәрнәрсәне һибә кылып бирүче». («Сад» сүрәсе, 35 нче аять)*

## Хәзрәти Әюбнең авыру чакта кылган догасы

Хәзрәти Әюб галәйһиссәлам, бик



www.darul-kutub.com

каты авыруга дучар ителгәч, Раббысына мөрәҗәгать иткән:

أَنِّ* مَسَّنِيَ الشَّيْطَانُ بِنُصْبٍ

**«Әннии мәссәнийә-ш шәйтаанү бинүсъб».**

*«Әй, Раббым! Мине шайтан авырлык белән сыпырды». («Сад» сурәсе, 41 нче аять)*

## Бер камил мөселман догасы

Үсеп җитеп бәлигъ булган ихлас күңелле мөселманның догасы Коръәндә китерелгән:

رَبِّ أَوْزِعْنِي أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِي أَنْعَمْتَ عَلَيَّ وَعَلَىٰ وَالِدَيَّ وَأَنْ أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضَاهُ وَأَصْلِحْ لِي فِي ذُرِّيَّتِي إِنِّي تُبْتُ إِلَيْكَ وَإِنِّي مِنَ الْمُسْلِمِينَ

**«Рабби әүзигьниии ән әшкүра нигьмәтәкә лләтии әнгәмтә гәләййә үә гәлә үәәлидәййә үә ән әгьмәлә саалихәң тәрдааһү үә әсълихь лии фии зүрриййәтии. Инниии түбтү иләйкә үә инниии минә-л мүслимиин».**

*«Йә, Раббым! Миңа илһам бир. Үземә һәм ата-анама биргән һидаят һәм Ислам нигъмәтенә шөкер итүем өчен, һәм Син риза була торган изге гамәлләр кылуым өчен, балаларымны да ислах ит, бар да мөэмин булсын. Йә, Раббым, мин Сиңа кайттым һәм мөселманнардан булып һәр әмереңә итәгать иттем». («Әхкаф» сурәсе, 15 нче аять)*

## Хәзрәти Нухның кяферләр кавеменә каршы кылган догасы

Хәзрәти Нух галәйһиссәламнең кавеменә озак вакытлар үгет-нәсыйхәтләр, дингә өндәүләр белән мөрәҗәгать итүеннән соң кылган догасы:

أَنِّي مَغْلُوبٌ فَانْتَصِرْ

**«Иннии мәгълүүбүң фәңтәсыйр».**

*«Чыннан да, мин җиңелдем. Йә, Раббым! Миңа ярдәм бир, алардан үч ал» («Камәр» (Ай) сурәсе, 10 нчы аять)*

www.darul-kutub.com

## Ихлас мөселманнар кылган дога

Коръән Кәримдә эчкерсез, ихлас күңелле мөселманнарның шулай дога кылганнары әйтелгән:

رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالْإِيمَانِ وَلَا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلًّا لِلَّذِينَ آمَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَءُوفٌ رَحِيمٌ

**«Раббәнә гъфир ләнәә үә ли ихъүәәнинә лләзиинә сәбәкуунәә би-ль имәәни үә ләә тәҗгәль фии кулүүбинәә гыйлләл лилләзиинә әәмәнүү раббәнәә иннәкә раүүфү-р рахиим».**

*«Йә, Раббыбыз! Безне ярлыка, бездән әүвәл иман белән дөньядан үткән дин кардәшләребезне дә ярлыка. Һәм безнең күңелләребездә урнаштырма иман китергән кешеләргә ачуны вә хөседне. Йә, Раббыбыз! Син, чыннан да, йомшак һәм рәхимле!» («Хәшер» сүрәсе, 10 нчы аять)*

## Коръәндә мөселманнарга өйрәтелгән дога

Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримдә мөселманнарга шушы доганы укырга киңәш иткән:

رَبَّنَا عَلَيْكَ تَوَكَّلْنَا وَإِلَيْكَ أَنَبْنَا وَإِلَيْكَ الْمَصِيرُ* رَبَّنَا لَا تَجْعَلْنَا فِتْنَةً لِلَّذِينَ كَفَرُوا وَاغْفِرْ لَنَا رَبَّنَا إِنَّكَ أَنْتَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ

**«Раббәнәә гәләйкә тәүәккәлнәә үә иләйкә әнәбнәә үә иләйкә-ль мәсыйр. Раббәнәә ләә тәҗгәлнәә фитнәтәл лилләзиинә кәфәруу үәгъфир ләнәә раббәнәә. Иннәкә әңтә-ль гәзиизү-л хәкиим».**

*«Йә, Раббыбыз! Без Сиңа тәвәккәл кылдык, тәүбә һәм итәгать белән Сиңа кайттык.*

Һәм ахырдан Синең хозурыңа кайтачакбыз. Йә, Раббыбыз, безне кяферләр кулына фетнә кылма, ягъни алар кулында мазлум булудан безне сакла вә безне ярлыка. Йә, Раббыбыз, шөбһәсез, Син куәтле, һәр эштә өстен һәм хикмәт белән эш кылучы». («Мүмтәханә» сүрәсе, 4-5 нче аятьләр)



www.darul-kutub.com

## Җәннәт әһелләре булган мөселманнарның кылган догалары

رَبَّنَا أَتْمِمْ لَنَا نُورَنَا وَاغْفِرْ لَنَا. إِنَّكَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Раббәнәәә әтмим ләнәә нүүранәә үәгъфир ләнәә. Иннәкә гәләә күлли шәй-иң кадиир».**

*«Йә, Раббыбыз! Безгә нурыбызны тутырып бир һәм гөнаһларыбызны ярлыка. Син, һичшиксез, һәрнәрсәгә кадирсең!» («Тәхрим» (Тыю) сурәсе, 8 нче аять)*

## Фиргавенгә каршы хатыны Асиянең кылган догасы

Аллаһ Тәгалә Коръән Кәримдә боерган:

«Янә Аллаһ мисал итеп зекер итте хакны кабул итүче мөэминнәргә Фиргавен хатыны Асиянең кыйссасын. Асия әйтте:

رَبِّ ابْنِ لِي عِنْدَكَ بَيْتًا فِي الْجَنَّةِ وَنَجِّنِي مِنْ فِرْعَوْنَ وَعَمَلِهِ
وَنَجِّنِي مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

www.darul-kutub.com

**«Рабби бни лии гиңдәкә бәйтәң фи-ль җәннәти үә нәҗҗинии миң фиргәүнә үә гәмәлиһи үә нәҗҗинии минә-ль кауми-з заалимиин».**

*«Йә, Раббым! Минем өчен Үзеңнең хозурыңда җәннәттә бер өй бина кыл һәм мине Фиргавеннән вә аның газабыннан коткар һәм Фиргавеннең залим булган кавеменнән мине коткар», – дип». («Тәхрим» (Тыю) сүрәсе, 11 нче аять)*

## Хәзрәти Нухның туфан башлангач кылган догасы

Туфан көчәеп, кәферләр бер-бер артлы суга бата башлагач, Хәзрәти Нух галәйһиссәлам дога кылган:

رَبِّ اغْفِرْ لِى وَلِوَالِدَىَّ وَلِمَنْ دَخَلَ بَيْتِىَ مُؤْمِنًا وَلِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَلَا تَزِدْ الظَّالِمِينَ إِلَّا تَبَارًا

**«Рабби гъфир лии үә лиүәәлидәййә үә лимәң дәхалә бәйти мүэминәү үә ли-ль мүэминиинә үә-ль мүэминәәт. Үә ләә тәзиди-з заалимиинә илләә тәбәәра»**

*«Йә, Раббым! Мине, мөселман булган ата-анам-*



www.darul-kutub.com

*ны ярлыка һәм минем өемә яки көймәмә мөэмин булып кергән кешене ярлыка һәм барча мөэмин ирләрне һәм мөэминә хатыннарны ярлыка! Залим кяферләргә арттырма һичнәрсәне, мәгәр һәлак булуларын гына арттыр!» («Нух» сүрәсе, 28 нче аять)*

## Пәйгамбәребезнең авыру кешеләр өчен кылган догасы

Коръән Кәримнең соңгы ике сүрәсе дә мәгънәсе ягыннан да, аңлату ысулы белән дә бер үк дога. Хәзрәти Гаишә (Аллаһ аннан разый булсын!) әйтеп калдырган:

«Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм кәефсезләнеп, үзен начар хис иткәндә, «Фәләкъ» белән «Нәс» сүрәләрен укып, үзенә өшкерә торган булган. Сырхаулары арта башлагач, шул сүрәләрнең ярдәм итүенә өметләнеп, догаларны мин укып, сулышымны аңа өрә һәм тәннәрен кулларым белән сыпыра идем». («Әт-Таҗ»: 4/24)

www.darulkutub.com

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ * مِنْ شَرِّ مَا خَلَق * وَمِنْ شَرِّ
غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ* وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ* وَمِنْ شَرِّ
حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ

**«Куль әгүүзү бирабби-ль фәләкъ. Миң шәрри мәә халәкъ. Үә миң шәрри гаасикыйн изәә үәкаб. Үә миң шәрри-н нәффәәсәәти фи-ль гүкадь. Үә миң шәрри хәәсидин изәә хәсәд».**

*«Әйт, Мөхәммәд: «Мин сыенам таңның Раббысы Аллаһ Тәгаләгә күренеп һәм күренмичә килә торган һәр төрле зарарлардан. Бар кылынган, яратылган һәр мәхлукның нинди булса да зарарыннан. Вә караңгы төннең зарарыннан сыгынам, һәркайчан караңгылыгы белән җир өстен капласа. Хәтта сихер-ырым төеннәренә төкеруче, өручe, сихерче хатыннар явызлыгыннан, зарарыннан сыгынам. Һәм көнче дошманның явызлыкларыннан, зарарларыннан сыенам, һәркайчан ул көнчелек ачуы белән зарар тидерергә теләсә» («Фәләкъ» (Таң) сурәсе, 1-5 аятьләр)*



www.darul-kutub.com

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ النَّاسِ* مَلِكِ النَّاسِ* إِلٰهِ النَّاسِ* مِنْ شَرِّ
الْوَسْوَاسِ الْخَنَّاسِ* الَّذِى يُوَسْوِسُ فِى صُدُورِ النَّاسِ* مِنْ
الْجِنَّةِ وَالنَّاسِ

**«Куль әгүүзү бирабби-н нәәс. Мәлики-н нәәс. Иләәһи-н нәәс. Миң шәрри-ль үәсүәәси-ль ханнәәс. Әлләзии йүүәсүисү фии судүүри-н нәәс. Минә-ль җиннәти үә-н нәәс».**

*«Әйт: «Кешеләрнең Раббысы булган Аллаһка сыгынам. Кешеләрнең патшасы булган Аллаһка сыгынам. Кешеләрнең гыйбадәт кыла торган Илаһәсе булган Аллаһка сыгынам. Чигенә-чигенә саваблы эштән тыеп, гөнаһлы эшкә өндәп вәсвәсә кылучы ханнәснең зарарыннан. Ул ханнәс кешеләрнең күңеленә явызлыкны сала. Ул ханнәс җеннәрдән дә һәм кешеләрдән дә бар». («Нәс» (Кешеләр) сурәсе, 1-6 аятьләр)*

## «Аятел Көрси»нең өстенлеге

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үәсәлләм Үбәй ибне Кәгебтән

www.darul-kutub.com

Коръән Кәримдәге иң бөек аятьне атарга сорагач, Үбәй «Аятел Көрси»не әйткән. Моңа җавап итеп, Аллаһ Расүле салләллаһу галәйһи үәсәлләм, аның күкрәгенә сугып, әйткән: «Әй, Әбә-л Мүнзир (үгетләүче)! Гыйлем сиңа мөбарәк булсын». («Рийазү-с Салихин», Н. 1017)

Тагын шулай дип тә әйтеп калдырганнар: «Һәр нәрсәнең бер югары ноктасы була. Коръәннең югары ноктасы – «Бакара» сүрәсе. Аның бер аяте бар – «Аятел Көрси».» («Әт-Таҗ»: 4/16)

## «Аятел Көрси»

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

اللهُ لَا إِلٰهَ إِلَّا هُوَ الْحَىُّ الْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ لَهُ مَا فِى السَّمٰوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِى يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمٰوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَا يَئُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِىُّ الْعَظِيمُ

**«Бисмилләәhи-р рахмәәни-р рахиим.**

**Аллааhу ләәә иләәhә илләәhү. Әлхәййүл каййүүм. Ләә тәәхузүhүү синәтү үә ләә нәүүм. Ләhүү мәә фи-с сәмәәүәәти үә мәә фи-ль әрдъ. Мәң зәлләзии йәшфәгү гиңдәhүү илләә би-изниh. Йәгьләмү мәә бәйнә әйдииhим үә мәә хальфәhүм. Үә ләә йүхиитуунә бишәй им мин гильмиhии илләә бимәә шәәәә. Үәсигә күрсиййүh-с сәмәәүәәти үә-ль әрдъ. Үә ләә йәүдүhүү хифьзуhүмәә үә hүүә-ль гәлийү-ль гәзыйм».**

*«Гыйбадәт кылырга яраклы hич бер зат юк, мәгәр Аллаh үзе генә. Ул hәрвакыт тере, бөтен нәрсәгә хуҗа булган хәлдә hәрвакыт бар. Аны ару, талу hәм йокы тотмас, җирдә hәм күкләрдә булган нәрсәләр аныкы. Ахирәттә Аллаh хозурында кем кемгә шәфәгать кылыр? Юк, шәфәгать кылучы булмас, hичкем үз теләге белән hичкемгә шәфәгать кыла алмас, мәгәр Аллаh рөхсәте белән генә шәфәгать кылучы булыр.*

Аллаh кешеләрнең үткәндәге барча эшләрен hәм алдагы барча эшләрен белер, кешеләр Аллаh белеменнән



www.darul-kutub.com

һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ белдергәнне генә белерләр. Аллаһның бушлык урыны җирне һәм күкләрне сыйдырды, Аллаһка җирне һәм күкләрне саклау авыр түгел, ул Аллаһ дәрәҗәдә бик бөек һәм бик олугъ». («Бакара» сүрәсе, 255 нче аять)

## Фәрештәләрнең мөселманнар өчен кылган догалары

Бу аятьләрдә фәрештәләрнең мөселманнар өчен кылган догалары һәм ярлыкауларын сорап үтенүләре бирелгән.

Хәсән Басри хәзрәтләре фәрештәләрнең шушы ярлыкау үтенечenә ишарәләп әйткән: «Намазыгызны сәхәр вакытына кадәр озайтыгыз. Чөнки сәхәр вакыты җитүгә фәрештәләр мөселманнар өчен Аллаһтан гафу сорый башлыйлар».

رَبَّنَا وَسِعْتَ كُلَّ شَيْءٍ رَحْمَةً وَعِلْمًا فَاغْفِرْ لِلَّذِينَ تَابُوا
وَاتَّبَعُوا سَبِيلَكَ وَقِهِمْ عَذَابَ الْجَحِيمِ* رَبَّنَا وَأَدْخِلْهُمْ
جَنَّاتِ عَدْنٍ الَّتِي وَعَدْتَهُم وَمَنْ صَلَحَ مِنْ آبَائِهِمْ

www.darul-kutub.com

وَأَزْوَاجِهِمْ وَذُرِّيَّاتِهِمْ إِنَّكَ أَنْتَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ* وَقِهِمْ
السَّيِّئَاتِ وَمَنْ تَقِ السَّيِّئَاتِ يَوْمَئِذٍ فَقَدْ رَحِمْتَهُ وَذَلِكَ هُوَ
الْفَوْزُ الْعَظِيمُ ۚ

**«Раббәнәә үәсигьтә күллә шәй ир рахмәтәү үә гильмәң фәгъфир лилләзиинә тәәбүү үәттәбәгүү сәбииләкә үә кыйһим гәзәәбә-ль җәхиим. Раббәнәә үә әдьхыйльһүм җәннәәти гәдни нилләти үәәдтәһүм үә мәң саләхә мин әәбәәәиһим үә әзүәәҗиһим үә зүррийййәәтиһим. Иннәкә әңтә-л гәзиизү-ль хәкиим. Үә кыйһимү-с сәййиәт. Үә мәң тәкый-с сәййиәәти йәүмәизиң фәкадҗ рахимтәһ. Үә зәәликә һүүә-ль фәүзү-ль гәзыйм».**

*«Йә, Раббыбыз! Синең рәхмәтең һәм Синең белемең һәрнәрсәне сыйдырды, тәүбә итеп, Синең юлыңа кергән, ягъни Коръән юлына кергән бәндәләреңне ярлыка һәм аларны Җәһәннәм газабыннан сакла! Йә, Раббыбыз! Вәгъдә кылган Гаден исемле Җәннәткә аларны кертегез, янә алар белән бергә Ислам динен дөрес тоткан ата-аналарын һәм хатыннарын һәм Коръән белән гамәл кылган балаларын да керт! Син, әлбәттә, һәр эштә галиб һәм*

*һәр эшне хикмәт белән эшлисең. Аларны дөньяда чакларында явыз эшләрдән сакла, берәүне Син дөньяда явызлыктан сакласаң, һичшиксез, Син аңа ахирәттә рәхмәт кылдың. Йә, Раббыбыз! Син берәүне дөньяда явызлыктан саклап та, ахирәттә Җәннәтле итсәң, бу эш олугъ изге теләккә ирешмәктер» («Мөэмин» сүрәсе, 7-9 нчы аятьләр)*

## Тиләвәт сәҗдәсе һәм сәҗдә аятьләре

Тиләвәт «уку» дигәнне аңлата. Бигрәк тә, Коръән Кәримне барлык кагыйдәләренә, ягъни тәҗвидкә туры китереп укуны аңлата. «Тиләвәт сәҗдәсе» дип намазда сәҗдә аятьләре дип аталган аятьләр укылганда кылынырга тиешле сәҗдәгә әйтәләр. Мондый аятьләр укылганда укыган кешегә дә, укыганны ишеткән кешегә дә сәҗдә кылу вәҗип. Сәҗдә аятьләре, шул аятьләр булган сүрәләр һәм аять номерлары шулар:

www.darulkutub.com

*1. «Әгъраф»: 206*

إِنَّ الَّذِينَ عِنْدَ رَبِّكَ لَا يَسْتَكْبِرُونَ عَنْ عِبَادَتِهِ وَيُسَبِّحُونَهُ وَلَهُ يَسْجُدُونَ

**«Иннә ллəзиинə гиңдә раббикә ләә йәстәкбируунә гән гибәдәтиһи үә йүсәббихүүнәһү үә ләһүү йәсҗүдүүн».**

«Һичшиксез, Раббың хозурында булган фәрештәләр Аллаһка гыйбадәт кылырга зурланмыйлар һәм Аллаһны мактап тәсбихләр әйтәләр һәм Аллаһка сәҗдә кылалар»

*2. «Рәгыд»: 15*

وَلِلهِ يَسْجُدُ مَنْ فِي السَّمٰوَاتِ وَالْأَرْضِ طَوْعًا وَكَرْهًا وَظِلَالُهُمْ بِالْغُدُوِّ وَالْاٰصَالِ

**«Үә лилләһи йәсҗүдү мәң фи-с сәмәәүәәти үә-ль әрдый таугәү үә кәрһәү үә зыйләәлүһүм би-ль гүдүүви үә-ль әәсаал».**

*«Җирдә һәм күкләрдә булган барча мәхлуклар кайберләре ихтыярый вә кайберләре ихтыярсыз*

www.darul-kutub.com

*Аллаһка сәҗдә кылырлар һәм иртәләрдә вә кичләрдә үзләре сәҗдә кылганда күләгәләре дә сәҗдә кылыр».*

*3. «Нәхел»: 49*

وَلِلهِ يَسْجُدُ مَا فِى السَّمٰوَاتِ وَمَا فِى الْأَرْضِ مِنْ دَابَّةٍ
وَالْمَلٰئِكَةُ وَهُمْ لَا يَسْتَكْبِرُونَ

**«Үә лилләһи йәсҗүдү мәә фи-с сәмәәүәәти үә мәә фи-л әрдый миң дәәәббәтиү үә-ль мәләәәикәтү үә һүм ләә йәстәкбируун».**

*«Җирдәге җан ияләреннән һәм күкләрдә булган нәрсәләр һәм фәрештәләр Аллаһка сәҗдә кылалар. Ул фәрештәләр Аллаһка сәҗдә кылудан зурланмаслар».*

*4. «Бәни Исраил» (Ягъкуб балалары): 107*

قُلْ اٰمِنُوا بِهِ أَوْ لَا تُؤْمِنُوا إِنَّ الَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ مِنْ قَبْلِهِ إِذَا
يُتْلٰى عَلَيْهِمْ يَخِرُّونَ لِلْأَذْقَانِ سُجَّدًا

**«Куль әәминүү биһии әү ләә түэминүү. Иннә лләзиинә үүтү-л гильмә миң кабьлиһиии изәә йүтләә гәләйһим йәхирруунә ли-ль әзкаани сүҗҗәдәә».**

*«Әйт: «Теләсәгез, ышаныгыз бу Коръәнгә, теләә-*



www.darulkutub.com

*мәсәгез – ышанмагыз, ихтыяр сезнеке. Ләкин Коръәнгә ышану, аның белән гамәл кылу белән булыр. Коръәннән элек иңгән китапны укый торган галимнәр, әгәр Коръән укылганны ишетсәләр, Аллаһны зурлап сәҗдә кылалар».*

*5. «Мәрьям»: 58*

أُوْلَئِكَ الَّذِينَ أَنْعَمَ اللهُ عَلَيْهِم مِنْ النَّبِيِّنَ مِنْ ذُرِّيَّةِ ادَمَ وَمِمَّنْ حَمَلْنَا مَعَ نُوحٍ وَمِنْ ذُرِّيَّةِ إِبْرٰهِيمَ وَإِسْرَائِيلَ وَمِمَّنْ هَدَيْنَا وَاجْتَبَيْنَا إِذَا تُتْلَى عَلَيْهِمْ ايَاتُ الرَّحْمٰنِ خَرُّوا سُجَّدًا وَبُكِيًّا

**«Үүләәәикә лләзиинә әнгәмәллааһү гәләйһим минә-н нәбиййиинә миң зүрриййәти әәдәмә үә миммән хәмәлнәә мәгә нүүхин. Үә миң зүрриййәти Ибрааһиимә үә исраааиилә үә миммән һәдәйнәә үәҗтәбәйнәә. Изәә түтләә гәләйһим әәйәәтү-р рахмәәни хәрруу сүҗҗәдәү үә бүкиййәә».**

*«Югарыда зекер ителгән пәйгамбәрләр, аларга Аллаһ пәйгамбәрлекне ингам кылды, Адәм галәйһиссәлам балаларыннан Идрисне, вә көймәдә Нух галәйһиссәлам белән бергә кутәрдек Без кешеләрнең балаларыннан Ибраһим галәйһиссәламне, вә Ибраһим балаларыннан Исмәгыйл, Исхак, Ягъкуб, Муса, Харун, Зәкәрия, Яхъя вә Гайсәләрне пәйгамбәр кыл-*



www.darulkutub.com

*дык. Ошбу зекер ителмеш затлар, Безнең тугры юлга кундерелмеш вә пәйгамбәрлеккә сайланмыш кешеләр. Әгәр аларга Аллаһның аятьләре укылса, сәҗдәгә китеп елыйлар»*

*6. «Хаҗ»: 18*

أَ لَمْ تَرَ أَنَّ اللهَ يَسْجُدُ لَهُ مَنْ فِي السَّمٰوَاتِ وَمَنْ فِي الْأَرْضِ وَالشَّمْسُ وَالْقَمَرُ وَالنُّجُومُ وَالْجِبَالُ وَالشَّجَرُ وَالدَّوَابُّ وَكَثِيرٌ مِنْ النَّاسِ وَكَثِيرٌ حَقَّ عَلَيْهِ الْعَذَابُ وَمَنْ يُهِنْ اللهُ فَمَا لَهُ مِنْ مُكْرِمٍ إِنَّ اللهَ يَفْعَلُ مَا يَشَاءُ

**«Әләм тәра әнналлааһә йәсҗүдү ләһүү мәң фи-с сәмәәүәәти үә мәң фи-ль әрдый үә-ш шәмсү үә-ль камәру үә-н нүҗүүүмү үә-ль җибәәлү үә-ш шәҗәру үә-д дәүәәәббү үә кәсиирум минә-н нәәс. Үә кәсиирун хәкка гәләйһи-ль гәзәәб. Үә мәй йүһинилләһү фәмәә ләһүү мим мүкрим. Инналлааһә йәфгәлү мәә йәшәәәэ».**

*«Беләсеңме, дөреслектә, Аллаһка җирдә һәм күкләрдә булган мәхлуклар сәҗдә кылалар: кояш, ай, йолдызлар, таулар, агачлар, хайваннар һәм куп кешеләр, вә кешеләрнең кубрәгенә динсез булганна-*



www.darul-kutub.com

*ры өчен газаб лязем булды! Аллаһ берәүне хур итсә, ул кешегә хөрмәт булмас. Әлбәттә, Аллаһ теләгән эшен эшләүче».*

*7. «Фуркан»: 60*

وَإِذَا قِيلَ لَهُمُ اسْجُدُوا لِلرَّحْمٰنِ قَالُوا وَمَا الرَّحْمٰنُ ۚ أَنَسْجُدُ
لِمَا تَأْمُرُنَا وَزَادَهُمْ نُفُورًا ۩

**«Үә изәә кыйлә ләһүм үсҗүдүү ли-р рахмәәни каалүү үә мә-р рахмәәну әнәсҗүдү лимәә тәәмүрунәә үә зәәдәһүм нүфүүра».**

«Мөшрикләргә Әррахмәнгә сәждә кылыгыз диелсә, әйтерләр: «Әррахмән нәрсә ул, синең әмерең белән белмәгән нәрсәгә сәждә кылыйкмы?» – дип. Аллаһка сәждә кылыгыз дигән сүз Аллаһтан качуларын арттырды».

*8. «Нәмел»: 25*

أَلَّا يَسْجُدُوا لِلهِ الَّذِى يُخْرِجُ الْخَبْءَ فِي السَّمٰوَاتِ وَالْأَرْضِ
وَيَعْلَمُ مَا تُخْفُونَ وَمَا تُعْلِنُونَ

**«Әлләә йәсҗүдүү лилләһилләзии йүхърижү-ль**



www.darul-kutub.com

**хаабь-ә фи-с сәмәәүәәти үә-ль әрдый үә йәгъләмү мәә түхъфүүнә үә мәә түгълинүүн».**

*«Янә һуд-һуд әйтте: «Әй, кешеләр, әгаһ булыгыз, җиргә яңгырны кушып төрле ризыклар чыгаручы Аллаһка гыйбадәт кылмаска нәрсә булган, янә Ул – Аллаһ күңелләрегездәге яшерен уйларыгызны һәм телләрегез сөйләгән сүзләрегезне белер».*

*9. «Сәҗдә»: 15*

إِنَّمَا يُؤْمِنُ بِآيَاتِنَا الَّذِينَ إِذَا ذُكِّرُوا بِهَا خَرُّوا سُجَّدًا وَسَبَّحُوا بِحَمْدِ رَبِّهِمْ وَهُمْ لَا يَسْتَكْبِرُونَ

**«Иннәмәә йүэминү биәәйәәтинә лләзиинә изә зүккирүү биһәә харрүү сүҗҗәдәү үә сәббәхүү бихәмди раббиһим үәә һүм лә йәстәкбирүүн».**

*«Безнең аятьләребезгә нык ышанучылар Коръән вәгазьләрен ишетсәләр, Аллаһтан куркып сәҗдә кылырлар һәм Аллаһ кимчелектән пакь диген игътикат белән Аны мактап тәсбихләр әйтерләр, ягъни Аллаһны зурлап намазлар укырлар, вә алар намаз укудан һәм Аллаһка итәгать итүдән тәкәбберләнмәсләр».*

*10. «Сад»: 24*

قَالَ لَقَدْ ظَلَمَكَ بِسُؤَالِ نَعْجَتِكَ إِلَىٰ نِعَاجِهِ وَإِنَّ كَثِيرًا مِنْ
الْخُلَطَاءِ لَيَبْغِي بَعْضُهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا
الصَّالِحَاتِ وَقَلِيلٌ مَا هُمْ وَظَنَّ دَاوُدُ أَنَّمَا فَتَنَّاهُ فَاسْتَغْفَرَ رَبَّهُ
وَخَرَّ رَاكِعًا وَأَنَابَ

**«Каалә ләкадь заләмәкә бисүәәли нәгъҗәтикә иләә нигәәҗиһ. Үә иннә кәсиирам минә-ль хуләтааа-и ләйәбгый бәгъдуһүм гәлә бәгъдин илләлләзиинә әәмәнүү үә гәмилү-с саалихәәти үә калиилүм мәә һүм. Үәзаннә дәәүүдү әннәмәә фәтәннәәһү фәстәгъфәра раббәһү үә харра раакигәү үә әнәәб».**

*«Дауд әйтте: «Туксан тугыз сарыгы була торып синең бер сарыгыңны сорап, сиңа золым иткән. Уртаклык белән эш кылучылардан, әлбәттә, бер-берсенә золым итәрләр, мәгәр иман китереп, изге гамәлләр кылган мөэминнәр золым итмәсләр, ләкин андый кешеләр аз». Фәрештәләр бу сүзләрне ишеткәч, Дауд үз зарарына хөкем итте, дип күккә аштылар. Дауд эшне аңлады, бу ике фәрештәнең аны сынар өчен һәм тәнбиһ итәр өчен килгәннәрен белде, Раббысыннан гафу сорады вә сәҗдәгә китте һәм тәүбә итте».*

www.darul-kutub.com

*11. «Фуссиләт»: 37*

وَمِنْ اٰيَاتِهِ اللَّيْلُ وَالنَّهَارُ وَالشَّمْسُ وَالْقَمَرُ لَا تَسْجُدُوا لِلشَّمْسِ وَلَا لِلْقَمَرِ وَاسْجُدُوا لِلهِ الَّذِى خَلَقَهُنَّ إِنْ كُنْتُمْ إِيَّاهُ تعْبُدُونَ

**«Үә мин әәйәәтиһи-ль ләйлү үә-н нәһәәру үә-ш шәмсү үә-ль камәр. Ләә тәсҗүдүү ли-ш шәмси үә ләә ли-ль камәри үәсҗүдүү лилләәһил ләзии халәкаһүннә иң күңтүм иййәәһү тәгьбүдүүн».**

*«Төннең вә көннең ятылышы, кояш вә айның төзелеше һәм хәрәкәтләре Аллаһның кодрәтенә вә берлегенә дәлиләт итә торган гамәлләрдән. Әй, кешеләр, кояшка һәм айга сәҗдә кылмагыз, чөнки алар да сезнең кебек мәхлукләр. Бәлки барча нәрсәне халык кылучы Аллаһка сәҗдә кылыгыз, әгәр сез Аллаһка гына гыйбадәт итә торган булсагыз?»*

*12. «Нәҗем»: 62*

فَاسْجُدُوا لِلهِ وَاعْبُدُوا

**«Фәсҗүдүү лилләәһи үәгьбүдүү».**

*«Аллаһка сәҗдә кылыгыз һәм гыйбадәт кылыгыз».*

www.darulkutub.com

*13. «Иншикак»: 21*

وَإِذَا قُرِئَ عَلَيْهِمُ الْقُرْآنُ لَا يَسْجُدُونَ

**«Үә изәә кури-ә гәләйһиму-л курь-әәну ләә йәсҗүдүүн».**

*«Әгәр аларга Коръән укылса, Аллаһтан куркып сәҗдә кылмаслар, Аллаһ әмерләрен ишеткәннән соң аны үтәмәсләр».*

*14. «Галәк»: 19*

كَلَّا لَا تُطِعْهُ وَاسْجُدْ وَاقْتَرِبْ

**«Кәлләә. Ләә түтыйгьһү үәсҗүд үәкътәриб».**

*«Юк, кирәкмәс, намаздан тыю бик яман кабахәт эш, аңа итәгать итмә, сүзенә колак салма, сәҗдә кыл, намаз укы һәм Аллаһка якын булуны кәсеп ит!»*

Әлеге аятьләр укылганда яки тыңланган вакытта тәкбир әйтеп, сәҗдә кылырга кирәк. Тәкбир басып торган килеш әйтелә, аннан соң сәҗдәгә китеп, өч тапкыр «Сүбхәәнә раббийә-л әгьлә» яки «Сүбхәәнә раббинәәә иң кәәнә үәгьдү раббинәә лә-мәфгүүлә» («Раббыбыз-

www.darul-kutub.com

ны һәр кимчелектән пакь дип беләбез, Раббыбызның әүвәлге китапларда «Мөхәммәд исемле пәйгамбәр җибәреп Коръән иңдерермен» дигән вәгъдәсе хак булды». «Бәни Исраил» сүрәсе, 108 нче аять) аятьләре укыла.

## Сәҗдә аятьләре белән дога кылу

Имам Нәсәфи әйткән:

«Бер мөселман сәҗдә аятьләрен бер мәҗлестә кабат-кабат укып, һәр аять алдыннан шунда ук сәҗдә кыла торган булса, Бөек Аллаһ Тәгалә аның догасын кабул итәр» («Тахтәви»: 272).

## «Йасин» сүрәсенең өстенлеге

«Йасин» Коръән Кәримдәге 36 нчы сүрәнең исеме. Төгәл мәгънәсе билгеле түгел. Шул ук вакытта, кайбер мөфәссирләр, тапшырылган риваятьләргә нигезләнеп, «Йасин» сүзенең «Әй, кеше!» дигән мәгънәдә килүен белдерәләр. Моның асылы «Йә Әнисин!» дигәннән гыйбарәт. Кыскартылган рәвештә

«Йәсин» килеп чыга. Моның максаты – Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам. «Йәсин» сүрәсе Мәккәдә иңдерелгән. Бары тик 45 нче аять кенә Мәдинәдә иңдерелгән. Әлеге сүрә 83 аять, 727 сүз һәм 3000 хәрефтән гыйбарәт. «Йәсин» сүрәсенең өстенлеге белән бәйле бик күп хәдисләр тапшырылган. Аларның кайберләрендә «Йәсин» сүрәсенең Коръәннең йөрәге дип аталуы турында сөйләнелә. Аллаһның Расүле әйткән:

«Һәр нәрсәнең йөрәге бар. Коръәннең йөрәге – «Йәсин» сүрәсе. «Йәсин»не укыган кешегә Аллаһ Тәгалә Коръәнне ун тапкыр укып чыккан савабын бирер» (Тирмизи, «Фәдаилү-л Куръән»: 7).

«Үлеләрегез өчен «Йәсин» сүрәсен укыгыз» («Фәйду-л Кадир»: 2/5).

www.darulkutub.com

## «Йасин» сүрәсе

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ
يٰس(١)وَالْقُرْاٰنِ الْحَكِيمِ(٢)إِنَّكَ لَمِنَ الْمُرْسَلِينَ(٣)عَلٰى
صِرَاطٍ مُسْتَقِيمٍ(٤)تَنزِيلَ الْعَزِيزِ الرَّحِيمِ(٥)لِتُنذِرَ قَوْمًا مَا
أُنذِرَ اٰبَاؤُهُمْ فَهُمْ غَافِلُونَ(٦)لَقَدْ حَقَّ الْقَوْلُ عَلٰى أَكْثَرِهِمْ
فَهُمْ لَا يُؤْمِنُونَ(٧)إِنَّا جَعَلْنَا فِي أَعْنَاقِهِمْ أَغْلَالًا فَهِيَ
إِلَى الْأَذْقَانِ فَهُمْ مُقْمَحُونَ(٨)وَجَعَلْنَا مِنْ بَيْنِ أَيْدِيهِمْ
سَدًّا وَمِنْ خَلْفِهِمْ سَدًّا فَأَغْشَيْنَاهُمْ فَهُمْ لَا يُبْصِرُونَ(٩)
وَسَوَاءٌ عَلَيْهِمْ أَأَنذَرْتَهُمْ أَمْ لَمْ تُنذِرْهُمْ لَا يُؤْمِنُونَ(٠١)إِنَّمَا
تُنذِرُ مَنِ اتَّبَعَ الذِّكْرَ وَخَشِيَ الرَّحْمٰنَ بِالْغَيْبِ فَبَشِّرْهُ بِمَغْفِرَةٍ
وَأَجْرٍ كَرِيمٍ(١١)إِنَّا نَحْنُ نُحْيِي الْمَوْتٰى وَنَكْتُبُ مَا قَدَّمُوا
وَاٰثَارَهُمْ وَكُلَّ شَيْءٍ أَحْصَيْنَاهُ فِي إِمَامٍ مُبِينٍ ۚ(٢١)وَاضْرِبْ
لَهُمْ مَثَلًا أَصْحَابَ الْقَرْيَةِ ۘ إِذْ جَاءَهَا الْمُرْسَلُونَ(٣١)
إِذْ أَرْسَلْنَا إِلَيْهِمُ اثْنَيْنِ فَكَذَّبُوهُمَا فَعَزَّزْنَا بِثَالِثٍ فَقَالُوا
إِنَّا إِلَيْكُمْ مُرْسَلُونَ(٤١)قَالُوا مَا أَنْتُمْ إِلَّا بَشَرٌ مِثْلُنَا وَمَا
أَنزَلَ الرَّحْمٰنُ مِنْ شَيْءٍ إِنْ أَنْتُمْ إِلَّا تَكْذِبُونَ(٥١)قَالُوا
رَبُّنَا يَعْلَمُ إِنَّا إِلَيْكُمْ لَمُرْسَلُونَ(٦١)وَمَا عَلَيْنَا إِلَّا الْبَلَاغُ
الْمُبِينُ(٧١)قَالُوا إِنَّا تَطَيَّرْنَا بِكُمْ لَئِنْ لَمْ تَنْتَهُوا لَنَرْجُمَنَّكُمْ

www.darulkutub.com

وَلَيَمَسَّنَّكُمْ مِنَّا عَذَابٌ أَلِيمٌ(٨١)قَالُوا طَائِرُكُمْ مَعَكُمْ
أَئِنْ ذُكِّرْتُمْ بَلْ أَنْتُمْ قَوْمٌ مُسْرِفُونَ(٩١)وَجَاءَ مِنْ أَقْصَى
الْمَدِينَةِ رَجُلٌ يَسْعٰى قَالَ يَاقَوْمِ اتَّبِعُوا الْمُرْسَلِينَ(٠٢)
اتَّبِعُوا مَنْ لَا يَسْأَلُكُمْ أَجْرًا وَهُمْ مُهْتَدُونَ(١٢)وَمَا لِى لَا
أَعْبُدُ الَّذِي فَطَرَنِي وَإِلَيْهِ تُرْجَعُونَ(٢٢)أَأَتَّخِذُ مِنْ دُونِه اٰلِهَةً
إِنْ يُرِدْنِي الرَّحْمٰنُ بِضُرٍّ لَا تُغْنِ عَنِّي شَفَاعَتُهُمْ شَيْئًا وَلَا
يُنقِذُونِ(٣٢)إِنِّ إِذًا لَفِي ضَلَالٍ مُبِينٍ(٤٢)إِنِّ اٰمَنْتُ
بِرَبِّكُمْ فَاسْمَعُونِ(٥٢)قِيلَ ادْخُلْ الْجَنَّةَ قَالَ يَالَيْتَ قَوْمِى
يَعْلَمُونَ(٦٢)بِمَا غَفَرَ لِى رَبِّى وَجَعَلَنِى مِنْ الْمُكْرَمِينَ(٧٢)
وَمَا أَنزَلْنَا عَلٰى قَوْمِهِ مِنْ بَعْدِه مِنْ جُندٍ مِنْ السَّمَاءِ وَمَا
كُنَّا مُنزِلِينَ(٨٢)إِنْ كَانَتْ إِلَّا صَيْحَةً وَاحِدَةً فَإِذَا هُمْ
خَامِدُونَ(٩٢)يَاحَسْرَةً عَلَى الْعِبَادِ مَا يَأْتِيهِمْ مِنْ رَسُولٍ
إِلَّا كَانُوا بِهِ يَسْتَهْزِئُون(٠٣)أَلَمْ يَرَوْا كَمْ أَهْلَكْنَا قَبْلَهُمْ مِنْ
الْقُرُونِ أَنَّهُمْ إِلَيْهِمْ لَا يَرْجِعُونَ(١٣)وَإِنْ كُلٌّ لَمَّا جَمِيعٌ
لَدَيْنَا مُحْضَرُونَ ع(٢٣)وَاٰيَةٌ لَهُمْ الْأَرْضُ الْمَيْتَةُ أَحْيَيْنَاهَا
وَأَخْرَجْنَا مِنْهَا حَبًّا فَمِنْهُ يَأْكُلُونَ(٣٣)وَجَعَلْنَا فِيهَا جَنَّاتٍ
مِنْ نَخِيلٍ وَأَعْنَابٍ وَفَجَّرْنَا فِيهَا مِنْ الْعُيُونِ(٤٣)لِيَأْكُلُوا
مِنْ ثَمَرِه وَمَا عَمِلَتْهُ أَيْدِيهِمْ أَفَلَا يَشْكُرُونَ(٥٣)سُبْحَانَ

www.darul-kutub.com

الَّذِى خَلَقَ الْأَزْوَاجَ كُلَّهَا مِمَّا تُنْبِتُ الْأَرْضُ وَمِنْ أَنفُسِهِمْ
وَمِمَّا لَا يَعْلَمُونَ(٦٣)وَاٰيَةٌ لَهُمْ اللَّيْلُ نَسْلَخُ مِنْهُ النَّهَارَ
فَإِذَا هُمْ مُظْلِمُونَ(٧٣)وَالشَّمْسُ تَجْرِي لِمُسْتَقَرٍّ لَهَا ذَٰلِكَ
تَقْدِيرُ الْعَزِيزِ الْعَلِيمِ(٨٣)وَالْقَمَرَ قَدَّرْنَاهُ مَنَازِلَ حَتَّى عَادَ
كَالْعُرْجُونِ الْقَدِيمِ(٩٣)لَا الشَّمْسُ يَنْبَغِى لَهَا أَنْ تُدْرِكَ
الْقَمَرَ وَلَا اللَّيْلُ سَابِقُ النَّهَارِ وَكُلٌّ فِي فَلَكٍ يَسْبَحُونَ(٠٤)
وَاٰيَةٌ لَهُمْ أَنَّا حَمَلْنَا ذُرِّيَّتَهُمْ فِي الْفُلْكِ الْمَشْحُونِ(١٤)
وَخَلَقْنَا لَهُمْ مِنْ مِثْلِه مَا يَرْكَبُونَ(٢٤)وَإِنْ نَشَأْ نُغْرِقْهُمْ فَلَا
صَرِيخَ لَهُمْ وَلَا هُمْ يُنقَذُونَ(٣٤)إِلَّا رَحْمَةً مِنَّا وَمَتَاعًا إِلٰى
حِينٍ(٤٤)وَإِذَا قِيلَ لَهُمْ اتَّقُوا مَا بَيْنَ أَيْدِيكُمْ وَمَا خَلْفَكُمْ
لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ(٥٤)وَمَا تَأْتِيهِمْ مِنْ اٰيَةٍ مِنْ اٰيَاتِ رَبِّهِمْ إِلَّا
كَانُوا عَنْهَا مُعْرِضِينَ(٦٤)وَإِذَا قِيلَ لَهُمْ أَنفِقُوا مِمَّا رَزَقَكُمْ
اللّٰهُ قَالَ الَّذِينَ كَفَرُوا لِلَّذِينَ اٰمَنُوا أَنُطْعِمُ مَنْ لَوْ يَشَاءُ اللّٰهُ
أَطْعَمَهُ ۚ إِنْ أَنْتُمْ إِلَّا فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ(٧٤)وَيَقُولُونَ مَتٰى
هٰذَا الْوَعْدُ إِنْ كُنتُمْ صَادِقِينَ(٨٤)مَا يَنظُرُونَ إِلَّا صَيْحَةً
وَاحِدَةً تَأْخُذُهُمْ وَهُمْ يَخِصِّمُونَ(٩٤)فَلَا يَسْتَطِيعُونَ
تَوْصِيَةً وَلَا إِلٰى أَهْلِهِمْ يَرْجِعُونَ ۝(٠٥)وَنُفِخَ فِي الصُّورِ
فَإِذَا هُمْ مِنْ الْأَجْدَاثِ إِلٰى رَبِّهِمْ يَنسِلُونَ(١٥)قَالُوا

يَاوَيْلَنَا مَنْ بعَثَنَا مِنْ مَرْقَدِنَا ۜ هٰذَا مَا وَعَدَ الرَّحْمٰنُ وَصَدَقَ
الْمُرْسَلُونَ(٢٥)إِنْ كَانَتْ إِلَّا صَيْحَةً وَاحِدَةً فَإِذَا هُمْ جَمِيعٌ
لَدَيْنَا مُحْضَرُونَ(٣٥)فَالْيَوْمَ لَا تُظْلَمُ نَفْسٌ شَيْئًا وَلَا تُجْزَوْنَ
إِلَّا مَا كُنتُمْ تعْمَلُونَ(٤٥)إِنَّ أَصْحَابَ الْجَنَّةِ الْيَوْمَ فِي
شُغُلٍ فَاكِهُونَ(٥٥)هُمْ وَأَزْوَاجُهُمْ فِي ظِلَالٍ عَلَى الْأَرَائِكِ
مُتَّكِئُونَ(٦٥)لَهُمْ فِيهَا فَاكِهَةٌ وَلَهُمْ مَا يَدَّعُونَ(٧٥)
سَلَامٌ قَوْلًا مِنْ رَبٍّ رَحِيمٍ(٨٥)وَامْتَازُوا الْيَوْمَ أَيُّهَا
الْمُجْرِمُونَ(٩٥)أَلَمْ أَعْهَدْ إِلَيْكُمْ يَابَنِى اٰدَمَ أَنْ لَا تَعْبُدُوا
الشَّيْطَانَ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُبِينٌ(٠٦)وَأَنْ اعْبُدُونِى هٰذَا
صِرَاطٌ مُسْتَقِيمٌ(١٦)وَلَقَدْ أَضَلَّ مِنْكُمْ جِبِلًّا كَثِيرًا أَفَلَمْ
تَكُونُوا تَعْقِلُونَ(٢٦)هٰذِه جَهَنَّمُ الَّتِ كُنتُمْ تُوعَدُونَ(٣٦)
اصْلَوْهَا الْيَوْمَ بِمَا كُنتُمْ تَكْفُرُونَ(٤٦)الْيَوْمَ نَخْتِمُ عَلى
أَفْوَاهِهِمْ وَتُكَلِّمُنَا أَيْدِيهِمْ وَتَشْهَدُ أَرْجُلُهُمْ بِمَا كَانُوا
يَكْسِبُونَ(٥٦)وَلَوْ نَشَاءُ لَطَمَسْنَا عَلٰى أَعْيُنِهِمْ فَاسْتَبَقُوا
الصِّرَاطَ فَأَنَّى يبْصِرُونَ(٦٦) وَلَوْ نَشَاءُ لَمَسَخْنَاهُمْ عَلَى
مَكَانَتِهِمْ فَمَا اسْتَطَاعُوا مُضِيًّا وَلَا يَرْجِعُونَ ۧ(٧٦)وَمَنْ
نُعَمِّرْهُ نُنَكِّسْهُ فِي الْخَلْقِ أَفَلَا يَعْقِلُونَ(٨٦)وَمَا عَلَّمْنَاهُ
الشِّعْرَ وَمَا يَنبَغِي لَهُ إِنْ هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ وَقُرْآنٌ مُّبِينٌ(٩٦)

www.darulkutub.com

لِيُنذِرَ مَن كَانَ حَيًّا وَيَحِقَّ الْقَوْلُ عَلَى الْكَافِرِينَ(٠٧)
أَوَلَمْ يرَوْا أَنَّا خَلَقْنَا لَهُمْ مِمَّا عَمِلَتْ أَيْدِينَا أَنْعَامًا فَهُمْ
لَهَا مَالِكُونَ (١٧) وَذَلَّلْنَاهَا لَهُمْ فَمِنْهَا رَكُوبُهُمْ وَمِنْهَا
يَأْكُلُونَ (٢٧) وَلَهُمْ فِيهَا مَنَافِعُ وَمَشَارِبُ أَفَلَا يَشْكُرُونَ
(٣٧) وَاتَّخَذُوا مِن دُونِ اللَّهِ آلِهَةً لَعَلَّهُمْ يُنصَرُونَ (٤٧)
لَا يَسْتَطِيعُونَ نَصْرَهُمْ وَهُمْ لَهُمْ جُندٌ مُّحْضَرُونَ (٥٧) فَلَا
يَحْزُنْكَ قَوْلُهُمْ إِنَّا نَعْلَمُ مَا يُسِرُّونَ وَمَا يُعْلِنُونَ(٦٧)أَوَلَمْ يرَ
الْإِنسَانُ أَنَّا خَلَقْنَاهُ مِنْ نُطْفَةٍ فَإِذَا هُوَ خَصِيمٌ مُبِينٌ(٧٧)
وَضَرَبَ لَنَا مَثَلًا وَنَسِيَ خَلْقَهُ قَالَ مَنْ يُحْيِ الْعِظَامَ وَهِيَ
رَمِيمٌ(٨٧)قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِى أَنشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ
خَلْقٍ عَلِيمٌ(٩٧)الَّذِي جَعَلَ لَكُمْ مِنْ الشَّجَرِ الْأَخْضَرِ
نَارًا فَإِذَا أَنْتُمْ مِنْهُ تُوقِدُونَ(٠٨)أَوَلَيْسَ الَّذِى خَلَقَ
السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ بِقَادِرٍ عَلَى أَنْ يَخْلُقَ مِثْلَهُمْ بَلَى وَهُوَ
الْخَلَّاقُ الْعَلِيمُ(١٨)إِنَّمَا أَمْرُهُ إِذَا أَرَادَ شَيْئًا أَنْ يَقُولَ لَهُ كُنْ
فَيَكُونُ(٢٨)فَسُبْحَانَ الَّذِي بِيَدِهِ مَلَكُوتُ كُلِّ شَيْءٍ وَإِلَيْهِ
تُرْجَعُونَ(٣٨)

www.darul-kutub.com

«Бисмилләәhи-р рахмәәни-р рахиим.

(1) Йәәсииин. (2) Үә-ль курьәәни-ль хәкиим. (3) Иннәкә ләминә-л мүрсәлиин. (4) Гәләә сыйраатыйм мүстәкыйм. (5) Тәңзиилә-ль гәзиизи-р рахиим. (6) Литүңзира каумәм мәәә үңзира әәбәәәүhүм фәhүм гаафилүүн. (7) Ләкадь хәкка-л каулү гәләәә әксәриhим фәhүм ләә йүьминүүн. (8) Иннәә җәгәлнәә фиии әгьнәәкыйhим агъләәләң фәhийә илә-ль әзкаани фәhүм мүкъмәhүүн. (9) Үә җәгәлнәә мим бәйни әйдииhим сәддәү үәмин хальфиhим сәддәң фә-әгъшәйнәhум фәhүм ләә йүбсыйрүүн. (10) Үә сәүәәәүн гәләйhим ә әңзәртәhүм әм ләм түнзирhум ләә йүьминүүн. (11) Иннәмәә түңзиру мәниттәбәгә-з зикра үә хашия-р рахмәәнә би-ль гайб. Фәбәшширhүү бимәгъфиратиү үә әҗриң кәриим. (12) Иннәә нәхнү нүхьйи-ль мәүтәә үә нәктүбү мәә каддәмүү үә әәсәәраhүм. Үә күллә шәй-ин әхьсайнәәhү фиии иməәмим мүбииин. (13) Үәдъриб ләhүм мәсәлән әсъхәәбә-ль карьйәh. Из җәәә-әhә-ль мүрсәлүүн. (14) Из әрсәлнәәә иләйhимү снәйни фәкәззәбүүhүмәә фәгәззәзнәә бисәәлисиң фәкаалүү иннәәә иләйкүм мүрсәлүүн. (15) Каалүү мәәә әңтүм илләә бәшәрум мислүнәә үә

мәә әңзәлә-р рахмәәну миң шәй-ин ин әңтум илләә тәкзибүүн. (16) Каалүү раббүнәә йәгыләмү иннәәә иләйкум ләмүрсәлүүн. (17) Үә мәә гәләйнәә илләә-ль бәләәгу-ль мүбиин. (18) Каалүү иннәә тәтаййәрнәә бикүм. Ләил ләм тәңтәһүү ләнәрҗүмәннәкүм үә ләйәмәссәннәкүм миннәә гәзааабүн әлиим. (19) Каалүү таааирукүм мәгәкүм. Ә иң зүккиртүм. Бәл әңтум каумум мүсърифүүн. (20) Үә җәәә ә мин әкъса-ль мәдиинәти раҗүлүй йәсгәәкаалә йәә кауми ттәбигү-ль мүрсәлиин. (21) Иттәбигү мәл ләә йәсьәлүкүм әҗрау үә һүм мүһтәдүүн. (22) Үә мәә лийә ләәә әгьбүдүлләзии фәтарании үә иләйһи түрҗәгүүн. (23) Ә әттәхыйзү миң дүүниһиии әәлиһәтән ий йүридни-р рахмәәну бидуррил ләә түгъни гәннии шәфәәгәтүһүм шәй-әү үә ләә йүңкыйзүүн. (24) Инниии изәл ләфии даләәлим мүбиин. (25) Иннииии әәмәңтү бираббикум фәсмәгүн. (26) Кыйлә дьхули-л җәннәһ. Каалә йәә ләйтә каумии йәгыләмүүн. (27) Бимәә гафәра лии раббии үә җәгәләнии минә-ль мүкьрамиин. (28) Үәмәәә әңзәлнәә гәләә каумиһии мим бәгьдиһии миң җүңдим минә-с сәмәәәи үә мәә күннәә мүңзилиин. (29) Иң кәәнәт илләә сайхәтәү үәәхидәтәң фәизәә һүм хаамидүүн. (30)

www.darulkutub.com

Йәә хасьратән гәлә-ль гибәәд. Мәә йәьтииһим мир расүүлин илләә кәәнүү биһии йәстәһзиүүн. (31) Әләм йәрау кәм әһләкнәә кабьләһүм минә-ль курууни әннәһүм иләйһим ләә йәрҗигүүн. (32) Үә иң күллүл ләммә җәмиигүл ләдәйнәә мүхьдаруун. (33) Үә әәйәтүл ләһүмү-ль әрду-ль мәйтәһ. Әхьйәйнәәһәә үә әхъраҗнәә минһәә хәббәң фәминһү йәькүлүүн. (34) Үә җәгәлнәә фииһәә җәннәтим мин нәхыйлиү үә әгьнәәбиү үә фәҗҗәрнәә фииһәә минә-л гүйүүн. (35) Лийәькүлүү миң сәмәриһи үә мәә гәмиләтһүү әйдииһим. Әфәләә йәшкүруун. (36) Сүбхәәнәлләзии халәка-ль әзьүәәҗә күлләһәә миммәә түмбитү-ль әрду үә мин әңфүсиһим үә миммәә ләә йәгьләмүүн. (37) Үә әәйәтүл ләһүмү-ль ләйл. Нәсләху минһү-н нәһәәра фәизәә һүм мүзълимүүн. (38) Үә-ш шәмсү тәҗрии лимүстәкаррил ләһәә. Зәәликә тәкъдииру-ль гәзиизи-ль гәлиим. (39) Үә-ль камәра каддәрнәәһү мәнәәзилә хәттәә гәәдә кә-ль гүрҗүүни-ль кадиим. (40) Лә-ш шәмсү йәмбәгый ләһәәә әң түдрикә-ль камәра үә лә-ль ләйлү сәәбику-н нәһәәр. Үәкүллүң фии фәләкий йәсбәхүүн. (41) Үә әәйәтүлләһүм әннәә хәмәлнәә зүрриййәтәһүм фи-ль фүлки-ль мәшхүүн. (42) Үә халәкънәә ләһүм мим мислиһии

мәә йәркәбүүн. (43) Үә ин нәшәә нүгърикъһүм фәләә сарииха ләһүм үә ләә һүм йүңказүүн. (44) Илләә рахмәтәм миннәә үә мәтәәгән иләә хиин. (45) Үә изәә кыйлә ләһүмү ттәкуу мәә бәйнә әйдиикүм үә мәә хальфәкүм ләгәлләкүм түрхәмүүн. (46) Үәмәә тәьтииһим мин әәйәтим мин әәйәәти раббиһим илләә кәәнүү гәнһәә мүгьридыйн. (47) Үә изәә кыйлә ләһүм әңфикуу миммәә разәкакүмүллаһу каалә лләзиинә кәфәруу лилләзиинә әәмәнүү ә нүтъгимү мәл ләү йәшәуллаһу әтъгәмәһ. Ин әңтүм илләә фии даләәлим мүбиин. (48) Үә йәкуулүүнә мәтәә һәәзә-ль үагьдү иң күңтүм саадикыйн. (49) Мәә йәңзууруунә илләә сайхәтәү үәхидәтәң тәьхузүһүм үә һүм йәхыйссыймүүн. (50) Фәләә йәстәтыйгүүнә тәүсыйәтәү үә ләәә иләәә әһлиһим йәрҗигүүн. (51) Үә нүфиха фи-с суури фәизәә һүм минә-ль әҗдәәси иләә раббиһим йәңсилүүн. (52) Каалү йәә үәйләнәә мәм бәгәсәнәә мим мәркадинәә. Һәәзәә мәә үәгәдә-р рахмәәнү үә садәка-ль мүрсәлүүн. (53) Иң кәәнәт илләә сайхәтәү үәәхидәтәң фәизәә һүм җәмиигүл ләдәйнәә мүхдаруун. (54) Фә-ль йәүмә ләә түзъләмү нәфсүң шәй-әү үә ләә түҗзәүнә илләә мәә күңтүм тәгьмәлүүн. (55) Иннә әсъхәәбәль җәннәти-ль йәүмә

www.darulkutub.com

фии шүгулин фәәкиһүүн. (56) Һүм үә әзүәәҗүһүм фии зыйләәлин гәлә-ль ә-рааик мүттәкиүүн. (57) Ләһүм фииһә фәәкиһәтү үә ләһүм мәә йәддәгүүн. (58) Сәләәмүң каулән мин раббир рахиим. (59) Үәмтәәзү-ль йәүмә әййүһә-ль мүҗримүүн. (60) Әләм әгьһәд иләйкум йәә бәниии әәдәмә әл ләә тәгьбүдү-ш шәйтаан. Иннәһүү ләкүм гәдүввүм мүбин. (61) Үә әнигьбүдүүнии. Һәәзәә сыйраатум мүстәкыйм. (62) Үә ләкадь әдаллә миңкүм җибилләң кәсиирә. Әфәләм тәкүүнүү тәгькыйлүүн. (63) Һәәзиһи җәһәннәмүл ләти күңтүм түүгәдүүн. (64) Исъләүһә-ль йәүмә бимәә күңтүм тәкфүрүүн. (65) Әл йәүмә нәхътимү гәлә әфьүәәһиһим үә түкәллимүнәә әйдииһим үә тәшһәдү әрҗүлүһүм бимәә кәәнүү йәксибүүн. (66) Үә ләү нәшәәәү ләтамәсьнәә гәләәә әгъьйүниһим фәстәбәку-с сыйраата фә-әннәә йүбьсыйрун. (67) Үә ләү нәшәәәү ләмәсәхънәәһүм гәләә мәкәәнәтиһим фәмә стәтаагүү мүдыййәү үә ләә йәрҗигүүн. (68) Үә мән нүгәммирһүү нүнәккисһүү фи-ль халькъ. Әфәләә йәгькыйлүүн. (69) Үәмәә гәлләмнәәһү-ш шигьра үә мәә йәмбәгый ләһ. Ин һүә илләә зикрун үә кур-әәнүм мүбиин. (70) Лийүңзира мәң кәәнә хәййәү үә йәхикка-ль каулү гәлә-ль кәәфириин. (71) Әүәләм

йәрау әннәә халәкънәә ләһүм миммәә гәмиләт әйдиинәәә әнгәәмәң фәһүм ләһәә мәәликүүн. (72) Үә зәлләлнәәһәә ләһүм фәминһәә ракүүбүһүм үә минһәә йәькүлүүн. (73) Үә ләһүм фииһәә мәнәәфигү үә мәшәәриб. Әфәләә йәшкүруун. (74) Үәттәхазүү миң дүүниллләһи әәлиһәтәл ләгәлләһүм йүңсаруун. (75) Ләә йәстәтыйгүнә нәсъраһүм үә һүм ләһүм җүңдүм мүхдаруун. (76) Фәләә йәхзүңкә каулүһүм иннәә нәгьләмү мәә йүсирруунә үә мәә йүгьлинүүн. (77) Әүәләм йәра-ль иңсәәнү әннәә халәкънәәһү мин нүтъфәтиң фәизәә һүвә хасыймүм мүбиин. (78) Үә дарабә ләнәә мәсәләү үә нәсийә халькаһ. Каалә мәй иүхьйиль гизаамә үә һийә рамиим. (79) Куль йүхьйииһә лләзиии әңшә-әһәә әүүәлә мәррраһ. Үә һүә бикүлли халькыйн гәлиим. (80) Әлләзи җәгәлә ләкүм минә-ш шәҗәри-ль әхдари нәәраң фәизәәә әңтүм минһү түүкыйдүүн. (81) Әүә ләйсә лләзии халәка-с сәмәәүәәти үә-ль әрда бикаадирин гәләәә әй йәхълүка мисләһүм. Бәләә үә һүә-ль халләәку-ль гәлиим. (82) Иннәмәәә әмруһүүү изәәә әраадә шәй-ән әй йәкуулә ләһүү күң фәйәкүүн. (83) Фәсүбхәәнәлләзии бийәдиһии мәләкүүтү кулли шәйиң үә иләйһи түрҗәгүүн.

www.darul-kutub.com

*Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахим.*

*(1) Йә син – мәгънәсен Аллаһ үзе генә белә. (2) Хикмәт иясе, ягъни шәригать хөкемнәре иясе булган Коръән белән ант итеп әйтәм. (3) Һичшиксез, син туры юлга күндерелмеш расүлләрдән. (4) Кешеләргә туры юлны күрсәтер өчен, Аллаһ тарафыннан җибәрелдең. (5) Ошбу Коръән Газиз вә Рахим булган Аллаһтан иңдерелгән изге дини китап. (6) Аталарына куркытучы пәйгамбәр җибәрелмәгән, вә туры юлдан гафил булган кавемне, Аллаһ газабы белән куркытуың өчен, сиңа иңдерелде. (7) Һичшиксез, ул кавемнең күбрәгенә газаб вәгъдәсе сабит булды, алар инде иман китермәсләр. (8) Һичшиксез, ул пәйгамбәрнең Аллаһ газабы белән куркытуы файда бирмәгән кавемнең муенына, иякләренә чаклы ирешкән киң богаулар кылдык, алар тәкәбберләнеп башларын күтәргәннәр, вә гафиллек белән күзләрен йомганнар, инде хакны күрүдән һәм белүдән мәхлукләрдер. (9) Янә аларның алларына да, артларына да пәрдә кордык һәм күзләрен капладык, алар үткән гомерләреннән һәм калган гомерләреннән гафилләр, хак белән ялганны һич аермаслар һәм туры юлны күрмәсләр. (10) Инде аларны Аллаһ газабы*



www.darul-kutub.com

*белән куркытсаң да, куркытмасаң да, алар өчен бертигез, һич иман китермәсләр. (11) Мәгәр син Коръән белән гамәл кылучы вә Аллаһ газабыннан курка белучене куркыта алырсың, андый кешеләр булса, аларны Аллаһның ярлыкавы һәм олугъ әҗерләре белән шатландыр! (12) Һичшиксез, Без үлекләрне тергезәбез, вә аларның үлмәстән элек кылган яхшы һәм яман эшләрен, һәм дә үзләре үлгәннән соң калдырган яхшы вә яман әсәрләрен язабыз. Без һәрнәрсәне санадык һәм яздык төп китапта. (13) Безнең расүлләребез Интакия халкын Ислам диненә өндәр өчен җибәрелгән вакытны мисал һәм гыйбрәт итеп кешеләргә сөйлә! (14) Без аларга ике пәйгамбәрне Ислам диненә өндәүче илче итеп җибәрсәк, алар илчеләрне ялганга тоттылар. Без аларны өченче илче белән куәтләдек. Бу өч пәйгамбәр Интакия халкына әйттеләр: «Без, һичшиксез, сезгә Ислам динен өйрәтү өчен җибәрелгән Аллаһның илчеләребез». (15) Кяферләр пәйгамбәрләргә әйттеләр: «Сез һичкем түгел, мәгәр безнең кебек гади кешеләр, Аллаһның сезгә һич нәрсә иңдергәне юк, Аллаһ безгә вәхи иңдерде, пәйгамбәр кылды, дип ялган сөйлисез». (16) Пәйгамбәрләр әйттеләр: «Әлбәттә, Раббыбыз белә,*

www.darul-kutub.com

*безнең сезне Ислам диненә өндәр өчен җибәрелгән илчеләр икәнлегебезне, сезне Ислам диненә өндәү һәм Аллаһ хөкемнәрен сөйләп сезгә ирештерү безгә лязем, без сезне көчләп иманга китерүче түгел». (18) Ул кяферләр әйттеләр: «Без сездән шомланабыз, әгәр безне үзегезнең динегезгә өндәүдән туктамасагыз, әлбәттә, бездән сезгә каты газаб ирешәчәк, ташлар белән бәреп үтерербез». (19) Пәйгамбәрләр әйттеләр: «Сезнең юлсыз шомлануыгыз үзегез белән бергә, әгәр сезгә шомлык килсә, үзегезнең явызлыгыгыздан килә.Әгәр иман китереп безнең сүзләребез белән вәгъдәләнсәгез, шомланмас идегез, ләкин сез һәр эшне урынсыз кылучы һәм гөнаһ кылуда чиктән ашкан кешеләрсез, шул сәбәпле хакны һич кабул итмисез». (20) Кяферләрнең ачуы килеп, пәйгамбәрләрне төрлечә газаплый башладылар. Бу хәлне ишетеп, шәһәр читеннән Хәбибун Нәҗҗар исемле ир пәйгамбәрләргә ярдәм итәргә дип ашыгып килде. Ул кеше пәйгамбәрләр шәһәргә килгәндә аларга иман китереп, мөселман булган иде. Кяферләр янына килгәч әйтте: «Йә, кавемем, бу пәйгамбәрләргә иярегез, алар хакны сөйлиләр, иман китереп мөселман булыгыз». (21) Ошбу пәйгамбәрләр Ислам динен*



www.darulkutub.com

*өйрәткәннәре өчен сездән хак сорамыйлар, үзләре туры юлга күнелгәннәр, аларга ияреп сез дә туры юлга керегез, дип. Кяферләр: «Безнең динне ташлап, боларның диненә ияреп сеңме», – диделәр. (22) Мөселман булган ир аларга әйтте: «Мине юктан бар иткән Раббыма ышанмаска һәм Аңа гыйбадәт кылмаска миңа ни булган, әлбәттә, Аллаһка ышанам һәм Аңа гына гыйбадәт кылам һәм Аңа гына итәгать итәм, сез үлгәннән соң терелеп, әлбәттә, шул Аллаһка җәза алыр өчен кайтарылачаксыз. (23) Әгәр Аллаһ миңа бер зарар ирештерүне теләсә, шул зарарны миннән җибәрергә һәм ул зарардан мине коткарырга көче җитмәгән сыннарга гыйбадәт кылыйммы, Аллаһны ташлап? (24) Әгәр мин Аллаһка гыйбадәт кылмыйча, башка нәрсәгә гыйбадәт кылсам, һәм Ислам динен кабул итмичә, башка бер батыйл диндә булсам, әлбәттә, мин ачык адашкан булырмын. Ул вакытта мине туры юлга кертүче табылмас». Бу мөселман булган Хәбибун Нәҗҗар пәйгамбәрләрне яклап, кяферләрне Ислам диненә өндәп күп кенә хак сүзләрне сөйләгәч, кяферләрнең хакка каршы ачулары кабарып, бу мөселманны ташлар белән атып һәм аяклары белән таптап*

www.darul-kutub.com

*үтерделәр. (25) Аның ахыр сүзе: «Әй, пәйгамбәрләр, ишетегез мин сезнең Раббыгызга иман китердем», – дигән сүз булды. (26) Бу мөселман шәһид булганнан соң, рухына фәрештәләр тарафыннан: «Җәннәткә кер», – диелде. Һәм ул әйтте: «Кавемем минем хәлемне чын белү белән белсәләрче?!» (27) Мөселман булганым хәлдә пәйгамбәрләрне һәм Ислам динен яклап шәһид булганым өчен, Раббым мине ярлыкаганың һәм Үзе хозурында хөрмәтлеләрдән кылганын белсәләрче? Әгәр хаклыкны яклап шәһид булу белән минем мәңгелек бәхеткә ирешкәнемне белсәләр, әлбәттә, Ислам динен кабул итеп үлгәнче хаклыкта булыр иделәр», – диде. (28) Пәйгамбәрләрне инкарь итеп һәм Хәбибүн Нәҗҗарны җәберләп үтергәннәреннән соң, Без аларны, ягъни Интакия кяферләрен һәлак итәр өчен күктән гаскәр иңдермәдек һәм кяферләрне һәлак итү өчен гаскәр иңдерү Безнең гадәтебез булмады. (29) Ул кяферләрне һәлак итүебез фәкать Җәбраил фәрештәнең бер мәртәбә кычкыруы белән булды, һәм алар сүнгән ут кебек һәлак булдылар. (30) Үзләрен Аллаһның рәхмәтенә вә җәннәтенә чакыру өчен килгән пәйгамбәрне инкарь итеп, төрлечә мәсхәрә кылучы*

www.darul-kutub.com

*кяферләрнең хәлләре ни укенечле һәм ни хәсрәтле һәм мәңгегә газабта калудыр. (31) Әйе, хәзерге кяферләр күрмиләрме, белмиләрме, әүвәлге кяферләрдән күпме кяфер шәһәрләрен һәлак иттек, ул һәлак булган кяферләр, һәлак булмаган кяферләр янына терелеп кайтмаслар.(32) Кешеләр кыямәт көнне һәммәсе Минем хозурыма җыелырлар. (33) Үлгән җирне су иңдереп, һаваны җылытып тергезүебез, әлбәттә, Безнең кодрәтебезгә һәм мәетләрне тергезәчәгебезгә ачык дәлилдер, вә ул җирдән кешеләр һәм хайваннар ашый торган күп төрле ризыклар чыгардык, шуларны уйлап карамыйлармы? (34) Янә Без җир өстендә хөрмә, йөзем бакчаларын бар кылдык һәм ул бакчаларда елгалар агыздык. (35) Җимешләрен кешеләр ашап файдалансыннар өчен ул бакчаларны халык кылдык, бит кешеләр ул җимешләрне берсен дә куллары белән ясамадылар, бәлки Аллаһ кодрәте белән төзелделәр, шуларны фикерләп Аллаһка шөкер итмиләрме? (36) Җир үстергән һәрнәрсәләрне вә кешеләрне, вә кешеләр белми торган нәрсәләрне, һәммәсен дә ирлехатынлы итеп төзүче Аллаһ һәр кимчелектән пакь. (37) Без кичтән көндезне суырып алабыз да кешеләр*

*һәм җир өсте караңгыда кала, бу эштә дә Аллаһның кодрәтенә дәлил бар. (38) Кояш Аллаһ билгеләгән вакытка чаклы үзенең юлында йөреп тора, кояшның шулай йөреше һәр эштә җиңүче һәм һәрнәрсәне белүче Аллаһ әмере беләндер. (39) һәм айның йөрешенә урыннар билгеләдек, хәтта ай беткәндә яки туганда күренештә нечкә булып хөрмә агачының кәкре нечкә ботагына охшап кала. (40) Кояшның айга ирешүе һәм кичнең көндездән элек килүе дөрес түгел, ягъни бу эш булмас, кояш белән ай һәм башкалары һәммәсе һава бушлыгында йөзеп йөриләр. (41) Янә Без адәм балаларын һәм аларның төрле әйберләрен, диңгезләрдә йөри торган корабларга йөкләдек, ягъни шулай тәкъдир кылдык. (42) Янә Без, кешеләр утырып йөрсеннәр өчен, корабка охшаган нәрсәләрне суда, һавада һәм корыда йөри торган күп нәрсәләр халык кылдык, ягъни тәкъдир кылдык. (43) Әгәр Без кешеләрне суга батырырга теләсәк, әлбәттә, батырырбыз, аларны коткарырга ярдәм табылмас һәм батып һәлак булудан коткарылмаслар. (44) Мәгәр Аллаһтан рәхмәт йөзеннән суга батырылмаслар, Аллаһ билгеләгән гомерләр беткәнче яшәсеннәр өчен. (45) Әгәр аларга: «Үзегездән әүвәлге кешеләргә килгән*

www.darulkutub.com

*газабтан һәм ахирәт газабыннан куркыгыз, шаять Аллаһыдан рәхмәт ителерсез», – дип әйтелсә, алар бу сүзләрдән баш тарталар. (46) Аларга Раббыларының аятьләреннән бер аять килсә, һич илтифат итмичә, ул аятьләрдән йөз дүндерәләр. (47) Әгәр мөшрикләргә: «Аллаһ биргән малдан фәкыйрьләргә сәдака бирегез», – диелсә, алар мөэминнәргә әйтәләр: «Аллаһ ризыкландырырга теләмәгән кешеләрне без ризыкландырыйкмы, аларны ризыкландыру тиеш булса, Аллаһ ризыкландырыр иде, Аллаһ теләмәгән эшкә безне өндисез, бу хакта сез ачык адашасыз». (48) Коръәнгә яки үлгәннән соң терелүгә ышанмаган кяферләр: «Үлгәннән соң терелү бар дисез, сезгә вәгъдә ителгән терелү көне кайчан була – безгә хәбәр итегез, әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз», – дип сорыйлар. (49) Ул кяферләр Аллаһтан һичнәрсә көтмиләр, ләкин фәрештәнең һәлак итә торган бер тавышын көтәләр, ул тавыш аларны сату-алу эшләрендә кычкырышкан вакытларында аңсыз тотар. Ул тавыш Исрафил фәрештәнең әүвәлге сур өрүедер. (50) Аларны ул тавыш тотканда васыятьләрен әйтергә һәм өй әһелләре янына кайтырга кадир булмаслар. (51) Сурга икенче мәртәбә*



www.darul-kutub.com

*өрелгәч, каберләреннән чыгып ашыга-ашыга Раббыларына барырлар. (52) Кяферләр каберләреннән кубарылып чыккач, безне йоклаган урыныбыздан кем кубарды, диярләр. Шуннан соң икърар кылып әйтерләр: «Бу көн – Раббыбыз вәгъдә иткән көн. Пәйгамбәрләр дә безгә хак сүзне сөйләгәннәр», – дип. (53) Фәкать сурның каты бер тавышы белән барча кешеләр Безнең хозурыбызгка килеп җыелырлар.(54) Бу көндә һичкемгә хаксыз золым итү булмас һәм һичкем кылган эшләре өчен җәза алмыйча да калмас. (55) Ул көндә җәннәткә кергән мөэминнәр, шиксез, яхшы нигъмәтләр белән ләззәтләнүчеләрдән була. (56) Ул мөэминнәр һәм хатыннары күләгәлектә яхшы диваннарда утырып шатланып сөйләшерләр. (57) Аларга җәннәттә тәмле җимешләр һәм күңелләре теләгән нәрсәләр бар. (58) Аларга җәннәттә рәхимле булган Аллаһтан сәлам бүләге дә ирешер. (59) Әй, имансыз динсезләр, яки Коръән белән гамәл кылмаучылар, Коръән белән гамәл кылучы мөселманнардан аерылыгыз! (60) Әй, Адәм балалары, Мин сезгә гаһед кылмадыммы һәм белдермәдемме шайтанга гыйбадәт кылмагыз һәм аның сүзе белән йөрмәгез, дип. Әлбәттә, ул сезгә ачык дошмандыр. (61) Сез*

www.darul-kutub.com

*Миңа гына гыйбадәт кылыгыз, Миңа гына гыйбадәт кылу һәм Мин күрсәткән юлдан гына бару – шул туры юл» – дип әйтмәдемме? (62) Һичшиксез, ул шайтан сезнең арагыздан бик күпләрне адаштырды, аздырды. Шуны уйлап карамыйсызмы? (63) Менә бу алдыгыздагы нәрсә, әгәр иман китермәсәгез һәм Аллаһка итәгать итмәсәгез, сезгә шул булыр дип, вәгъдә ителгән җәһәннәмдер. (64) Дөньяда имансыз, динсез булганыгыз өчен, бүген шул җәһәннәмгә кереп, аның каты газабын татыгыз! (65) Мәхшәр көнендә кяферләрнең һәм монафикъларның авызларына мөһер басарбыз һәм эшләгән эшләрен кулларыннан сөйләтербез һәм аякларын шаһит итәрбез. (66) Әгәр теләсәк, аларның күзләрен томалап сукыр кылыр идек, гадәтләре буенча ашыгып юлга чыгарлар, ләкин сукыр булулары сәбәпле юлны һич күрмәсләр. (67) Әгәр теләсәк, торган яки йөргән урыннарында аларның сурәтләрен алыштырыр идек, кайтырга да, китәргә дә кадир булмаслар иде. (68) Әгәр берәүгә озын гомер бирсәк, аның әгъзаларына зәгыйфьлек бирәбез. Шуны уйлап карамыйлармы?(69) Без Мөхәммәд галәйһиссәламгә шигырь өйрәтмәдек һәм аңа шагыйрь булу дөрес тә түгел. Ләкин Без аңа*

*вәгазь һәм ачык мәгънәле Коръән өйрәттек. (70) Ул Коръән тере кешеләрне Аллаһ газабы белән куркытыр өчен һәм аның белән гамәл кылмаучы кяферләргә җәһәннәм газабын лязем итәр өчен иңдерелде. (71) Ул кяферләр белмиләрме, һичшиксез, Без аларга үз кодрәтебез белән дүрт аяклы хайваннар халык кылдык, алар бу хайваннарга хуҗа булдылар. (72) Вә ул хайваннардан файдаланырга ирекле кылдык, ул хайваннардан әйберләрен төяп үзләре дә утырып, хезмәт өчен файдалана торганнары да бар һәм ул хайваннарның итләрен дә ашыйлар. (73) Һәм ул хайваннарда аларга төрле файдалар бар һәм эчемлекләр дә бар. Шуларның барын да Аллаһ биргән дип, Аллаһка шөкер итмиләрме? (74) Мөшрикләр, шаять безгә ярдәм итәрләр, дип, Аллаһтан башка илаһлар ясап, аларга гыйбадәт кылалар. (75) Мөшрикләрнең ясаган сыннары үзләре өчен хәзерләгән гаскәрләре булса да, аларга ярдәм итәргә кадир булмаслар. (76) Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, кяферләрнең мәгънәсез яман сүзләре өчен хәсрәтләнмә! Без аларның күрсәтеп эшләгән эшләрен дә һәм яшереп эшләгән эшләрен дә beләбез, тиешле җәзасын бирербез. (77) Әллә кеше белмиме, Безнең аны бер тамчы судан ха-*

www.darulkutub.com

*лык кылганыбызны, шуның соңында ул зәгыйфь кеше Безнең белән каты каршылашамы, үтергәнебездән соң, аны яңадан тергезергә кадир икәнлегебезне инкарь итәме? (78) Үзенең бер тамчы судан халык кылынганлыгын онытып, кипкән сөяк белән Безгә мисал итеп, бу сөяк череп беткәч, моны кем тергезә алыр, дип. (79) Син аларга әйт: «Бу сөякне әүвәл мәртәбәдә кем юктан бар кылган булса, шул зат тергезер», – дип. Ул – Аллаһ, барча мәхлукның хәлен белүче. (80) Ул – Аллаһ, сезнең өчен яшел агачта ут бар кылды, сез ул агачны сугып ут яндырасыз, яшел һәм сулы агачтан ут чыгарган Аллаһ мәетләрне тергезергә, әлбәттә, кадирдер. (81) Җир һәм күкләрне яраткан Аллаһ, кешеләр кебек кечкенә нәрсәләрне халык кылырга кадир түгелме? Әлбәттә, кадир һәм Ул Яратучы һәм белүчедер. (82) Аллаһ бер нәрсәнең бар булуын теләсә, ул нәрсәгә фәкать, бар бул, дип әйтер һәм ул нәрсә бар булыр. (83) Барча нәрсәгә хуҗалык, Аның кулында булган Аллаһ һәр кимчелектән пакь, һәм Аңа кире кайтарылырсыз».*

www.darulkutub.com

## «Әсмәү-ль Хүснә»

«Әсмәү-ль Хүснә» Аллаһ Тәгаләнең күркәм исемнәре дигәнне аңлата. Аллаһ Тәгаләнең дүрт мең исеме бар. Коръән Кәримдә безгә әлеге исемнәрнең 99ы белдерелгән». (Хаммами, «Йәсин тәфсире»: 2)

Әбү Һүрайра (Аллаһ аннан разый булсын!) Аллаһ Рәсүленең әйткәннәрен тапшырган: «Аллаһ Тәгаләнең туксан тугыз шәрифле исеме бар. Аларны санап чыккан кеше Җәннәткә керәчәк». (Тирмизи, «Дәват»: 83)

Аллаһ Тәгалә боерган: «Аллаһның күркәм исемнәре бар, шул исемнәр белән дога кылыгыз! Әмма Аллаһка тиешсез исем бирүчеләрдән качыгыз! Аллаһка тиешсез исем биргәннәре өчен җәза кылынырлар». («Әгъраф» сүрәсе, 180 нче аять)

Аллаһ Тәгаләнең аятьләрдә һәм хәдисләрдә расланган туксан тугыз исеме:

www.darul-kutub.com

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

هُوَ اللهُ الَّذِي لَا إِلٰهَ إِلَّا هُوَ, الرَّحْمٰنُ, الرَّحِيمُ , الْمَلِكُ,
الْقُدُّوسُ, السَّلَامُ, الْمُؤْمِنُ, الْمُهَيْمِنُ, الْعَزِيزُ, الْجَبَّارُ,
الْمُتَكَبِّرُ, الْخَالِقُ, الْبَارِئُ, الْمُصَوِّرُ, الْغَفَّارُ, الْقَهَّارُ,
الْوَهَّابُ, الرَّزَّاقُ, الْفَتَّاحُ,الْعَلِيمُ, الْقَابِضُ, الْبَاسِطُ,
الْخَافِضُ, الرَّافِعُ, الْمُعِزُّ, الْمُذِلُّ, السَّمِيعُ, الْبَصِيرُ,
الْحَكَمُ, الْعَدْلُ, اللَّطِيفُ, الْخَبِيرُ, الْحَلِيمُ, الْعَظِيمُ, الْغَفُورُ,
السَّكُورُ, الْعَلِيُّ, الْكَبِيرُ, الْحَفِيظُ, الْمُقِيتُ, الْحَسِيبُ,
الْجَلِيلُ, الْكَرِيمُ, الرَّقِيبُ, الْمُجِيبُ, الْوَاسِعُ, الْحَكِيمُ,
الْوَدُودُ, الْمَجِيدُ, الْبَاعِثُ, الشَّهِيدُ, الْحَقُّ, الْوَكِيلُ,
الْقَوِيُّ, الْمَتِينُ, الْوَلِيُّ, الْحَمِيدُ, الْمُحْصِى, الْمُبْدِئُ,
الْمُعِيدُ, الْمُحْيِ, الْمُمِيتُ, الْحَيُّ, الْقَيُّومُ, الْوَاجِدُ,
الْمَاجِدُ, الْوَاحِدُ, الْأَحَدُ, الصَّمَدُ, الْقَادِرُ, الْمُقْتَدِرُ,
الْمُقَدِّمُ, الْمُؤَخِّرُ, الْأَوَّلُ, الْاخِرُ, الظَّاهِرُ, الْبَاطِنُ, الْوَالِى,
الْمُتَعَالِى, الْبَرُّ, التَّوَّابُ, الْمُنْتَقِمُ, الْعَفُوُّ, الرَّؤُوفُ, مَالِكُ
الْمُلْكِ, ذُو الْجَلَالِ, وَ الْإِكْرَامِ, الْمُقْسِطُ, الْجَامِعُ, الْغَنِيُّ,
الْمُغْنِى, الْمَانِعُ, الضَّارُّ, النَّافِعُ, النُّورُ, الْهَادِى, الْبَدِيعُ,
الْبَاقِى, الْوَارِثُ, الرَّشِيدُ, الصَّبُورُ.

Бисмил-ләһир-рахмәәнир-рахиим.

Һүәллаһулләзии ләәә иләәһә илләәһү, әр-Рахмәән, әр-Рахиим, әл-Мәлик, әл-Куддүүс, әс-Сәләәм, әл-Мүэмин, әл-Мүһәймин, әл-Гәзииз, әл-Җәббәәр, әл-Мүтәкәббир, әл-Хаалик, әл-Бәәри, әл-Мүсаууьвир, әл-Гаффәәр, әл-Каhhәәәр, әл-Үәhhәәб, әр-Раззәәкъ, әл-Фәттәәх, әл-Гәлиим, әл-Каабидъ, әл-Бәәситъ, әл-Хаафидъ, әр-Раафигь, әл-Мүгизз, әл-Мүзилл, әс-Сәмиигь, әл-Басыйр, әл-Хәкәм, әл-Гәәдил, әл-Ләтыйфь, әл-Хабиир, әл-Халиим, әл-Гәзыйм, әл-Гафүүр, әш-Шәкүүр, әл-Гәлийй, әл-Кәбиир, әл-Хәфиизъ, әл-Мүкыйть, әл-Хәсииб, әл-Җәлиил, әл-Кәриим, әр-Ракыйб, әл-Мүҗииб, әл-Үәәсигь, әл-Хакиим, әл-Үәдүүд, әл-Мәҗиид, әл-Бәәгис, әш-Шәһиид, әл-Хәккъ, әл-Үәкиил, әл-Кауий, әл-Мәтиин, әл-Үәлий, әл-Хамиид, әл-Мүхьсый, әл-Мүбдиэ, әл-Мүгиид, әл-Мүхьйи, әл-Мүмиит, әл-Хәййү, әл-Каййүүм, әл-Үәәҗид, әл-Мәәҗид, әл-Үәәхид, әл-Әхәд, әс-Самәд, әл-Каадир, әл-Мүкътәдир, әл-Мүкаддим, әл-Мүәххыйр, әл-Әүәәл, әл-Әәхыйр, әз-Зааһир, әл-Бәтыйн, әл-Үәәли, әл-Мүтәгәәлии, әл-Бәрр, әт-Тәүүәәб, әл-Мүңтәкыйм, әл-Гәфүүв, әр-Рәүүф, Мәәликүль-Мүлк, Зүл - Җәләәли үәл- Икрам, әл-Мүкъситъ, әл-Җәәмигь, әл-Ганий, әл-

**Мүгъни, әл-Мәәнигь, әд-Даарр,ән-Нәәфигь, ән-Нүүр, әл-һәәди, әл-Бәдиигь, әл-Бәәкый, әл-Үәәрис, әр-Рашиид, әс-Сабүүр.**

*1. Аллаһ – Бөек Яратучыбызның зат исеме. Башка исемнәр Аның фигыйльләре, сыйфатлары һәм Илаһи көчләре белән бәйле.*
*2. Рахман – барлыкка китергән барлык мәхлукларына нигъмәт бирүче.*
*3. Рахим – ахирәттә бары тик мөселманнарга гына рәхмәт итүче, ярлыкаучы.*
*4. Мәлик – һәр нәрсәнең хакиме, хуҗасы.*
*5. Куддүс – кимчелекләрдән пакь.*
*6. Сәлам – иминлек һәм тынычлык бирүче.*
*7. Мөэмин – ышаныч һәм иминлек бирүче.*
*8. Муһәймин – Үзенә буйсындыручы.*
*9. Газиз – Бөек, җиңелмәс.*
*10. Җаббар – бар нәрсә белән идарә итүче.*
*11.Мөтәкаббир – чын бөеклеккә бердәнбер ия булучы.*
*12. Халик – барлыкка китерүче.*
*13. Бари – юктан барлыкка китерүче, яратучы.*
*14. Мосаувир – бар нәрсәгә калып, рәвеш бирүче.*
*15. Гаффар – гөнаһларны ярлыкаучы.*



www.darulkutub.com

*16. Каһһәр – һәлак итүче, җәза бирүче.*
*17. Вәһһәб – чиксез бүләкләүче.*
*18. Раззәкъ – бәрәкәт һәм ризык бирүче.*
*19. Фәттах – игелек һәм бәрәкәт капкаларын ачучы.*
*20. Галим – бар нәрсәдән хәбәрдар.*
*21. Кабид – җаннарны алучы.*
*22. Бәсит – яшәү өчен мөмкинлекләр бирүче һәм гомерләрне озайтучы.*
*23. Хафид – имансызларны түбәнсетүче.*
*24. Рафигъ – иманлыларның дәрәҗәсен күтәрүче.*
*25. Мөгыйз – кадер-хөрмәткә һәм зур дәрәҗәләргә ирештерүче.*
*26. Мөзил – хур итүче һәм түбәнсетүче.*
*27. Самигъ – бар нәрсәне ишетүче.*
*28. Бәсыйр – бар нәрсәне күрүче.*
*29. Хаким – яхшыны яманнан аеручы бөек хаким.*
*30. Гадел – дөрес, турылыклы, гадел.*
*31. Латыйф – колларга мәрхәмәт итүче.*
*32. Хәбир – бар нәрсәне белүче.*
*33. Хәлим – түбәнчелекле.*
*34. Газыйм – бөекләрнең бөеге.*
*35. Гафур – бик күп тапкырлар гафу кылучы.*
*36. Шәкүр – тиеш булганнан артык савап бирүче.*

www.darul-kutub.com

*37. Галийй – бөек һәм бөеклеккә ирештеручe.*
*38. Кәбир – бөек, Аның каршында бар нәрсә бик вак.*
*39. Хафиз – саклаучы.*
*40. Мукыйт – игелекләр булдыручы.*
*41. Хәсиб – хисап алучы.*
*42. Җәлил – Бөек сыйфатларга ия булучы.*
*43. Кәрим – юмартларның юмарты.*
*44. Ракыйб – күзәтеп торучы.*
*45. Мүҗиб – дога һәм үтенечләрне кабул итүче.*
*46. Вәсигъ –чиксез мәрхәмәт һәм белемнәр иясе.*
*47. Хәким – акыл иясе.*
*48. Вәдуд – мөселманнарны яратучы.*
*49. Мәҗиид – иң хөрмәтле һәм бөек дәрәҗәдәге.*
*50. Бәгыйс – пәйгамбәрләрне җибәрүче.*
*51. Шәһид – бар нәрсәгә шаһит.*
*52. Хакк – иң дөрес.*
*53. Вәкил – яклаучы.*
*54. Кавий – иң көчле.*
*55. Мәтин – көчлеләрдән көчле.*
*56. Вәлий – иманлыларга, мөселманнарга ярдәм итүче.*
*57. Хәмид – мактауга лаеклы.*
*58. Мухсый – барысын да исәпләүче.*

www.darul-kutub.com

*59. Мубдигъ – барлыкка китеруче.*
*60. Мугыйд – утереп, яңадан терелтуче.*
*61. Мухйи – җан кертуче, гомер бируче.*
*62. Мумит – утеруче.*
*63. Хәййу – башлангычы һәм ахыры булмаган, мәңге исән.*
*64. Кайюм – барлыкка китерелгән һәр нәрсәгә тереклек бируче.*
*65. Вәҗид – бай һәм ихтыяҗы булмаган.*
*66. Маҗид – юмартлыгы һәм бөеклеге бөек булучы.*
*67. Вахид – бердәнбер, тиңе булмаган.*
*68. Самәд – бернигә дә мохтаҗлыгы булмаучы.*
*69. Кадир – чиктән тыш куәтле.*
*70. Муктәдыйр – бик көчле, бар нәрсәне иң камил дәрәҗәдә булдыручы.*
*71. Мукаддим – Үзе теләгәннәрне алдынгы итуче.*
*72. Муаххир – артка җибәруче.*
*73. Әувәл – башлангычы булмаган.*
*74. Ахыйр – ахыры булмаган.*
*75. Заһир – ачыктан-ачык, барлыгы шиксез булучы.*
*76. Бәтыйн – яшерен, бу дөньяда куренмәс.*
*77. Вәәли – бар нәрсәнең Хөкемдары.*
*78. Мутәгали – Галиҗәнап.*

www.darul-kutub.com

*79. Бәрр – игелекле, бөек шәфкатькә ия булучы.*
*80. Тәуваб –тәубәләрне кабул итүче.*
*81. Мунтәкыйм – буйсынмаучыларга үзләренең әҗерен бирүче.*
*82. Гафув – гафу итүче.*
*83. Рәуф – түбәнчелекле.*
*84. Мәликуль-мулк – бар нәрсәнең мәңгелек хуҗасы.*
*85. Зул-Җәләли вәл-Икрам – чын бөеклек һәм юмартлык иясе.*
*86. Муксит – гадел.*
*87. Җәмигъ – теләгәннәрне теләгән вакытта һәм теләгән урында җыючы.*
*88. Ганий – бик бай, беркемнең дә ярдәменә мохтаҗ булмаучы.*
*89. Мугъни – теләгәнен баетучы.*
*90. Мәнигъ – тыючы, тоткарлап калучы.*
*91. Дарр – Үзе теләгәннәрне игелекләрдән мәхрүм итүче.*
*92. Нәфигъ – Үзе теләгән кешегә күп файда китерүче.*
*93. Нур – иман нуры бирүче.*
*94. Һади – Үзе теләгәннәрне тугры юлга кертүче.*
*95. Бәдыйгъ – иң күркәм рәвештә барлыкка китерүче.*
*96. Бәкый – мәңгелек, ахырсыз, чиксез.*

www.darul-kutub.com

*97. Варис – хакыйкый мирас иясе.*
*98. Рәшид – тугры юлга кундеручe.*
*99. Сабур – Сабыр.*

## Шайтанның мәкереннән саклану өчен

Ибн Мәсүд (Аллаһ аннан разый булсын!) Аллаһ Рәсүле саләллаһу галәйһи вәссәламнең әйткәннәрен тапшырган: «Иртән «Бакара» сүрәсеннән ун аять укыган кешегә шайтан кичкә кадәр якына алмас. Ахшамда укыган кешегә исә шайтан иртәнге намаз вакытына кадәр якыная алмас».

Ибне Мәсүд (Аллаһ аннан разый булсын!) шулай ук Табәри белән Хаким тапшырган хәдиснең дөреслеген ассызыклап, аның эчтәлеген китергән: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Бакара» сүрәсенең башыннан дүрт аять, «Аятел Көрси»не, аннан соңгы ике аятьне һәм «Бакара» сүрәсенең соңгы аятьләрен

укыган кешенең өенә иртәнге намазга кадәр шайтан керә алмас» (Бәйхаки, Табәрани). Укыла торган аятьләр алга таба китерелгән:

أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيطَانِ الرَّجِيمِ

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

الم* ذٰلِكَ الْكِتَابُ لَا رَيْبَ فِيهِ هُدًى لِلْمُتَّقِينَ* الَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِالْغَيْبِ وَيُقِيمُونَ الصَّلٰوةَ وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنفِقُونَ* وَالَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِمَا أُنْزِلَ إِلَيْكَ وَمَا أُنْزِلَ مِنْ قَبْلِكَ وَبِالْاٰخِرَةِ هُمْ يُوقِنُونَ* أُوْلٰئِكَ عَلٰى هُدًى مِنْ رَبِّهِمْ وَأُوْلٰئِكَ هُمْ الْمُفْلِحُونَ .

**«Әгузү билләһи минә-ш шайтани-р раҗим. Бисмилләһи-р рахмани-р рахим.**

**Әлиф ләм мим. Зәликә-ль китабу лә райбәфиһ. Худән ли-ль муттәкыйн. әлләзинә йуэминунә би-ль гайби вә йукыймунә-с саләтә вә миммә разакнәһүм йунфикун. Вәлләзинә йуэминунә бимә унзилә иләйкә вә мә унзилә мин каблик. Вәби-ль ахирати һүм йукыйнун. Үләэикә галә раббиһим вә үләэикә һүмү-ль муфлихун»**

*«Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән. Әлиф ләм мим – мәгънәсен Аллаһ үзе генә белә. Коръәннең Аллаһтан иңдерелгән хак китап булуына һич шик юк, бу китап аның белән гамәл кылучы тәкъва мөэминнәргә хак юлны күрсәтүче һидаят. Ул тәкъва мөэминнәр күрмәсә дә, күргән кебек Аллаһка ышаналар. һәм йөкләтелгән намазларны вакытында укыйлар, һәм Без биргән байлыктан сәдакалар бирәләр. Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, ул тәкъва мөэминнәр сиңа иңдерелгән Коръәнгә ышанып, аның буенча гамәл кылалар һәм синнән элек иңдерелгән китапларга да ышаналар һәм ахирәткә дә ышанып, аның өчен гамәл кылалар. Ул тәкъва мөэминнәр Раббылары тарафыннан туры юлга күнечүләр һәм алар ахирәттә өстенлек табучылар». («Бакара» (Сыер) сүрәсе, 1-5 нче аятьләр)*

www.darul-kutub.com

СОДЕРЖАНИЕ

КОРЪӘНДӘГЕ ДОГАЛАР........................................3

ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ СӨННӘТЕНДӘ ДОГА..............................................11

ДОГА АЯТЬЛӘРЕ........................................................15

Хәзрәти Адәмнең белеменнән хайран калган фәрештәләрнең догасы ..........................................17

Хәзрәти Ибраһимнең Кәгъбә нигезе янында кылган догасы ......................................................17

Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнең дөнья һәм ахирәткә кагылышлы догалары ...........................................19

Җалутка каршы чыккан мөселманнарның догасы ....................................20

Пәйгамбәрләр һәм тәкъва мөселманнары догасы ..........................................21

Туры юлдан тайпылмаган галимнәрнең догасы..............................................22

Тәкъва мөселманнары догасы...............................23

Коръәндә Пәйгамбәребезгә укырга боерылган дога.........................................24

www.darul-kutub.com

Хәзрәти Мәрьям тугач
кылынган дога ..........................................25

Хәзрәти Зәкәрийянең бала сорап
кылган догасы ..........................................26

Хәвариләр (Гайсә пәйгамбәрнең шәкертләре)
догасы......................................................26

Гаделсезлеккә дучар булган
мөселманнарның догасы ..............................27

Гыйбрәт күрә белүче аңлы
мөселманнар догасы ..................................28

Җәберләнгән кешеләрнең золымнан
котылу өчен кылган догасы ..........................30

Хәзрәти Мусаның имансызлар кавеменә
каршы кылган догасы ..................................31

Хәзрәти Гайсәнең ризык сорау догасы ..............32

Пәйгамбәребезнең Мәккәдә кылган догасы.........33

Хәзрәти Адәм белән Хәзрәти Һаваның
кылган догалары ........................................33

Җәннәткә лаек булганнарның Җәһәннәм
әһелләрен күргәч кылган догалары......................34

Хәзрәти Шогайбның җәберләүчеләр кавеменә
каршы кылган догасы ..................................35

Хәзрәти Мусага инанган сихерчеләрнең догасы ...36

www.darul-kutub.com

Хәзрәти Мусаның Раббысы Бөеклегеннән тәэсирләнеп кылган догасы.................................36

Кавеменең кылган гамәлләреннән борчылган/кайгырган Хәзрәти Мусаның догасы.........................37

Кавеменең кылган гамәлләреннән борчылган Хәзрәти Мусаның догасы......................................37

Хәзрәти Мусага иманучыларның догасы.............38

Хәзрәти Нухның кяфер углы өчен кылган догасы ..................................................39

Үзенә тозак корылуын белгән Хәзрәти Йосыфның кылган догасы.......................40

Хәзрәти Йосыфның Мисыр патшасы булгач кылган догасы ..................................................42

Хәзрәти Ибраһимнең Кагъбәдә кылган беренче догасы .......................................43

Хәзрәти Ибраһимның барлык мөселманнар өчен кылган догасы..............................................45

Ата-ана өчен дога кылу .......................................46

Әсъхәәбү Кәһф кылган догалары ........................48

Хәзрәти Мусаның телендәге тотлыгуны бетерүне сорап кылган догасы.............................48

Пәйгамбәребезгә гыйлемгә кагылышлы өйрәтелгән дога................................49



www.darulkutub.com

Хәзрәти Әюбнең авыруыннан котылдыруны сорап кылган догасы ..........50
Хәзрәти Йонысның балык карнында чакта кылган догасы ..........51
Хәзрәти Зәкәрийянең бала сорап кылган догасы ..........51
Хәзрәти Нухның үз кавеменә каршы кылган догасы ..........52
Хәзрәти Нухның туфан вакытында кылган догасы ..........52
Пәйгамбәребезнең мөшрикләргә каршы кылган догасы ..........53
Пәйгамбәребезнең шайтан вәсвәсәсеннән котылу өчен кылган догасы ..........53
Коръәндә мөселманнар догасы ..........54
Коръәндә барлык мөселманнарга өйрәтелгән дога ..........55
Тәкъва мөселманнары кыла торган дога ..........55
Ихлас мөселманнар кылган дога ..........56
Хәзрәти Ибраһимның хөкем догасы ..........57
Хәзрәти Лутның бозык кавеменә каршы кылган догасы ..........58

www.darul-kutub.com

Хәзрәти Сөләйманның ата-анасы өчен
кылган догасы ........................................................58

Хәзрәти Мусаның Мисырда кылган догасы.........59

Хәзрәти Лутның кавеме өчен
кылган догасы ........................................................60

Хәзрәти Ибраһимнең бала сорап
кылган догасы ........................................................61

Фәрештәләр догасы..............................................61

Хәзрәти Сөләйманның мөлкәт
сорап кылган догасы...........................................62

Хәзрәти Әюбнең авыру чакта кылган догасы......62

Бер камил мөселман догасы...............................63

Хәзрәти Нухның кяферләр кавеменә
каршы кылган догасы .........................................64

Ихлас мөселманнар кылган дога........................65

Коръәндә мөселманнарга өйрәтелгән дога...........65

Җәннәт әһелләре булган мөселманнарның
кылган догалары ..................................................67

Фиргавенгә каршы хатыны Асиянең
кылган догасы ........................................................67

Хәзрәти Нухның туфан башлангач
кылган догасы ........................................................68

www.darul-kutub.com

Пәйгамбәребезнең авыру кешеләр өчен
кылган догасы ..........................................................69

«Аятел Көрси»нең өстенлеге ..................................71

«Аятел Көрси»........................................................72

Фәрештәләрнең мөселманнар өчен
кылган догалары .....................................................74

Тиләвәт сәждәсе һәм сәждә аятьләре ......................76

Сәждә аятьләре белән дога кылу ............................86

«Йасин» сүрәсенең өстенлеге ..................................86

«Йасин» сүрәсе.........................................................88

«Әсмәү-ль Хүснә» ...................................................111

Шайтанның мәкереннән саклану өчен...............119

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com